# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

## 2001 елга Татарстан Республикасының бюджет системасы турында

1 статья. 2001 елга Татарстан Республикасының республика бюджетын керемнәр буенча – 20924209 мең сум күләмендә һәм чыгымнар буенча 22565560 мең сум күләмендә расларга.

2001 елга Татарстан Республикасының республика бюджеты кытлыгының иң чик суммасын 1641351 мең сум күләмендә билгеләргә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты 2001 елда кредит оешмаларыннан алынган кредитларны, Татарстан Республикасы исеменнән чыгарылучы кыйммәтле кәгазьләрне урнаштырудан алынган средстволарны, Татарстан Республикасының дәүләт милкендәге мөлкәтне сатудан алына торган керемнәрне Татарстан Республикасының республика бюджеты кытлыгын каплауга юнәлдерергә тиеш.

2 статья. 2001 елга Татарстан Республикасының республика бюджеты керемнәре түбәндәгеләр исәбеннән барлыкка килә дип билгеләргә:

- предприятиеләр һәм оешмалар табышына (керемена) салымның бер өлеше;
- физик затларның керемнәренә салымның бер өлеше;
- предприятиеләр мөлкәтенә салымның бер өлеше;
- уен бизнесына салым – Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән минималь ставкалардан артыграк исәпләнгән салым суммасының 50 проценты күләмендә;
- Татарстан Республикасы территориясендә җитештерелә торган азык-төлек чималыннан ясалган этил спирты чималына, азык-төлек чималыннан (чимал спирттан кала) ясалган этил спиртына, эчә торган спиртка, аракыга һәм ликер-аракы эчемлекләренә, спиртлы эремәләргә акцизлар - керемнәрнең 50 проценты күләмендә;
- Татарстан Республикасы территориясендә җитештерелә торган сырага, тәмәкегә, ювелир әйберләргә акцизлар - керемнәрнең 100 проценты күләмендә;
- Россия Федерациясе законнары нигезендә лицензия һәм теркәү җыемнары;

- чит ил акчаларын һәм чит ил валютасы белән белдерелгән түләү документларын сатып алган өчен салым - Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына күчерү өчен Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән нормативлар буенча;
- җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен түләүләрнең бер өлеше;
- сатудан салымның бер өлеше - Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән нормативлар буенча;
- Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетына күчерелергә тиешле суммадан 50 процент күләмендә алына торган җир өчен салым һәм җир өчен аренда хакы;
- Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетына күчерелергә тиешле салым суммасының 50 проценты күләмендә оешмалар түли торган эшчәнлекнең аерым төрләре өчен каралган керемгә бердәй салым;
- Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетына күчерелергә тиешле салым суммасыннан табышка салым нормативлары буенча кече эшкуарлык субъектлары - оешмалар өчен барлык керемнән алына торган бердәм салымнын бер өлеше;
- Татарстан Республикасынын берләштерелгән бюджетына күчерелергә тиешле мәҗбүри медицина иминиятенә түләүләр буенча ставка өлешендә бердәм социаль салым;
- федераль бюджеттан барлык төр финанс ярдәме;
- керемнәрнең 100 проценты күләмендә автомобиль юлларыннан файдаланучыларга салым;
- керемнәрнен 100 проценты күләмендә транспорт чаралары хуҗаларыннан салым;
- минераль-чимал базасын янадан торгызу өчен түләүләрнен бер өлеше;
- максатчыл бюджет фондлары акчалары.

<u>3 статья.</u> Татарстан Республикасынын республика бюджеты керемнәрендә уртактан эшләү өчен чимал буларак бирен торылган нефтьне Татарстан Республикасыннан читтә эшкәрткәндә ягулык-майлау материалларын сатуга салым, автотранспорт чараларын сатып алуга салым, автомобиль юлларыннан файдаланучыларга салым, минераль-чимал базасын янадан торгызу өчен түләүләр, шулай ук штрафлар (административ тәртиптә салына торган штрафларнын 15 процентыннан гайре), һәм элегрәк әлеге салымнарнын Татарстан Республикасынын Юллар фондына, Татарстан Республикасынын Минераль ресурс запасларын янадан торгызу һәм файдалы казылмалар чыгаруның нәтиҗәлелеген арттыру фондына түләнәсе өлешен вакытында түләмәгән өчен җыелган пенялар буенча 2001 елның 1 гыйнварена җыелган бурычны түләү исәбенә салым түләүчеләрдән керә торган акчалар исәпкә алына дип билгеләргә.

Татарстан Республикасының Эш белән тәэмин итү дәүләт фонды, Татарстан Республикасында Юллар фонды, Татарстан Республикасынын Минераль ресурслар запасларын торгызу һәм

файдалы казылмалар чыгаруның нәтиҗәлелеген арттыру фондынын элек төзелгән шартнамәләр (килешүләр) нигезендә оешмалар тарафыннан кире кайтарыла торган акчалары, 2001 елнын 1 гыйнвареннан башлап, Татарстан Республикасынын республика бюджеты керемнәренә кертелә.

Бөлгенлеккә төшү һәм финанс савыктыру гамәлләрен тәэмин итү махсуслаштырылган фондының элек төзелгән шартнамәләр (килешүләр) нигезендә оешмалар тарафыннан кире кайтарыла торган акчалары, 2001 елның 1 гыйнвареннан башлап, Татарстан Республикасының Хосусыйлаштыру фонды керемнәренә кертелә.

4 статья. 2001 елга файдалы казылмалар чыгару өчен түләү ставкаларын чыгарылган ресурсларны сату бәясенә карата түбәндәге процентларда билгеләргә:

| Файдалы казылмаларның (чималның) төрләре | Ставка |
|---|---|
| 1. Нефть һәм газ | 6 |
| 2. Табигый битум | 4 |
| 3. Гипс ташы | 4 |
| 4. Фосфоритлар | 4 |
| 5. Цемент чималы | 4 |
| 6. Туфракны известьлау өчен карбонат токымнары | 3 |
| 7. Карбонат токымнары | 3 |
| 8. Киселгән таш | 3 |
| 9. Бут һәм вак таш өчен төзелеш ташы | 3 |
| 10. Ком-гравий катнашмасы | 4 |
| 11. Пыяла һәм формалау комы | 4 |
| 12. Төзелеш комы | 3 |
| 13. Бентонит балчыклары | 4 |
| 14. Керамзит балчыклары | 4 |
| 15. Кирпеч балчыклары | 2,5 |
| 16. Глауконитлар, цеолитлар | 4 |
| 17. Торф, торфовивианит | 3 |
| 18. Җир асты сулары | 6 |
| 19. Файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен түләү (күрсәтелгән хезмәтләр бәясеннән чыгып) | 2 |

2001 елга жир асты байлыкларыннан файдаланган өчен ләүләр Татарстан Республикасы бюджетына күчерелә торган ешендә түбәндәгечә бүленә, дип билгеләргә (процентларда):

| Түләүләрнең төрләре | Бюджетлар буенча бүленеш | |
|---|---|---|
| | республика | шәһәрләр һәм районнар |
| Файдалы казылмаларны чыгарган өчен түләү: | | |
| - торф, сапропель, жир асты сулары һәм минераль сулар буенча; | - | 100 |
| - гомумтаралган файдалы казылмалар буенча; | - | 100 |
| - нефть, газ, Идел һәм Кама елгалары үзәннәреннән чыгарылучы ком-вак таш катнашмасы, табигый битум, гипс ташы, цемент чималы буенча; | 70 | 30 |
| - файдалы казылмаларнын калган төрләре (фосфоритлар, бентонит балчыклары, керамзит балчыклары, төзелеш известе өчен карбонат токымнары, киселгән таш, пыяла һәм формалау комы, глауконитлар, цеолитлар) буенча | - | 100 |
| Файдалы казылмаларны лицензияләрдә билгеләнгәннән һәм лимитлардан (квоталардан) артыграк кулланган өчен түләүләр 5 мәртәбәгә артыграк ставка буенча алына; - нормативлардан тыш куллануны билгеләгән орган счетына - 10 процент | 60 | 30 |
| Файдалы казылмаларны чыгаруга бәйле булмаган жир асты байлыкларыннан файдаланган өчен түләү | 50 | 50 |

5 статья. 2001 елга минераль-чимал базасын яңадан торгызуга үләүләрнең ставкасын фактта чыгарылган файдалы казылмалардан ынган һәм сатылган беренче товар продукты хакыннан чыгып, роцентларда түбәндәгечә билгеләргә:

| Файдалы казылмаларның (чималның ) төрләре | Ставка |
|---|---|
| 1. Нефть, газ һәм конденсат | 10,0 |
| 2.Ташкүмер | 5,0 |
| 3. Торф | 3,0 |
| 4. Радиоактив чимал | 3,0 |
| 5. Тимер һәм хром рудалары | 3,7 |
| 6. Төсле һәм сирәк металлар | 8,2 |
| 7. Затлы металлар | 7,8 |
| 8. Алмазлар, пьезооптик, үтә чиста кварц һәм асылташ чималлар | 3,5 |
| 9. Апатитлар һәм фосфоритлар | 3,1 |
| 10. Калий тозлары | 1,7 |
| 11. Җир асты суларын да кертеп, башка файдалы казылмалар | 5,0 |

6 статья. Предприятиеләр, оешмалар һәм чит илләрнең юридик затлары мөлкәтенә салым ставкасын салым салынучы базаның 2 проценты күләмендә билгеләргә. Түләүнең квартал сроклары бозылган очракта билгеләнгән тәртиптә пеня исәпләргә.

Автомобиль җитештерүче предприятиеләрнең мөлкәтенә, аларның иярчен предприятиеләрен дә кертеп, салым ставкасын салым салынучы базаның 1 проценты күләмендә билгеләргә. Әлеге предприятиеләрнең исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

2001 елда, мөлкәтнең суммар инвентаризация кыйммәтеннән чыгып, физик затларның корылмаларына, биналарына һәм төзелмәләренә салым ставкасын түбәндәге күләмнәрдә билгеләргә:

| Мөлкәтнең суммар инвентаризация кыйммәте | Салым ставкасы |
|---|---|
| 600 мең сумга кадәр | 0,1 процент |
| 601 мең сумнан 1000 мең сумга кадәр | 0,5 процент |
| 1001 мең сумнан 1500 мең сумга кадәр | 1 процент |
| 1500 мең сумнан артканда | 1,5 процент |

7 статья. Реинвестицияләүгә юнәлдерүне исәпкә алып, дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштырудан алынган акчалар бюджетлар һәм Хосусыйлаштыру фонды арасында түбәндәге нормативлар буенча бүленә:

а) Татарстан Республикасының Хосусыйлаштыру фонды һәм Татарстан Республикасының республика бюджеты арасында

53

(процентларда)

| | Татарстан Республикасынын Хосусыйлаштыру фондына | Татарстан Республикасының республика бюджетына | Коммуналь мөлкәткә идарә итү жирле комитетларына |
|---|---|---|---|
| хосусыйлаштырудан алынган акчаларның гомуми суммасы | 90 | 10 | - |
| шул исәптән: Коммуналь мөлкәткә идарә итү комитетлары тарафыннан арендага бирелә торган республика мөлкәтеннән файдаланган өчен аренда түләүләреннән алынган акчалар суммасы | 80 | 10 | 10 |

б) төрле дәрәҗәдәге бюджетлар арасында:

(процентларда)

| Объектларны хосусыйлаштырудан | Татарстан Республикасының республика бюджетына | Җирле бюджетларга |
|---|---|---|
| Республика милкендәге | 100 | |
| Коммуналь милектәге | | 100 |

8 статья. Предприятиеләрнең, оешмаларның табышына (керемнә) Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетына күчерелә торган салым ставкаларын түбәндәгечә билгеләргә:

а) предприятиеләр, оешмалар һәм чит илләрнең юридик затлары өчен - 19 процент күләмендә;

б) предприятиеләр өчен - арадашчы гамәлләреннән һәм алыш-биреш итүләрдән, биржалардан, брокер контораларыннан, банклардан, башка кредит һәм иминият оешмаларыннан алынган табыш буенча - 27 процент күләмендә.

2001 елга бюджетны раслаганда халык депутатларының жирле Советларына предприятиеләрнең, оешмаларның табышына (керемнә) 5 процент күләмендә өстәмә (19 проценттан тыш) керем салымы ставкасын раслауны тәкъдим итәргә.

54

9 статья. “Алабуга” ирекле икътисадый зонасында катнашучыларга “Алабуга” ирекле икътисадый зонасы турында” Татарстан Республикасы Законының 8 статьясы нигезендә өстенлекле салым ташламалары бирергә.

10 статья. Җинел сәнәга предприятиеләрен Татарстан Республикасының республика бюджетына керүче салымнар һәм җыемнар (бердәм социаль салымдагы һәм бердәй керем салымындагы мәҗбүри медицина иминиятенә түләү ставкаларыннан, сатудан салымнан гайре) түләүдән азат итәргә.

Дәүләт хакимиятенең җирле органнарына җирле бюджетларга күчерелүче салымнар һәм җыемнар өлешендә шундый ук карарлар кабул итүне тәкъдим итәргә.

11 статья. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына предприятиеләрнең яна производстволар оештыру һәм гамәлдәгеләрен яңарту буенча хупланган бизнес-проектлары өчен инвестициячел салым кредитлары бүлеп бирү хокукы бирергә.

12 статья. 2001 елга сәнәга предприятиеләре һәм башка товар җитештерүчеләр Татарстан Республикасының республика бюджетын 2001 елга формалаштырганда исәпкә алынган фараз күрсәткечләреннән артыграк җитештерелгән продукция (башкарылган эшләр, күрсәтелгән хезмәтләр) составында өстәлгән бәягә кертелгән күләмдә табышка салымның Татарстан Республикасының республика бюджетына күчерелә торган өлешен түләүдән азат ителәләр дип билгеләргә.

Югарыда күрсәтелгән предприятиеләрнең һәм оешмаларның агымдагы түләүләрне вакытында һәм тулысынча тәэмин итүләре аларга өстенлекле ташламалар бирүнен шарты булып тора. Агымдагы түләүләрне кертү сроклары кварталга ике тапкырдан да артыграк үтәлмәгәндә, алынмый калган керемнәр шул ук кварталда компенсацияләнсә, өстенлекле ташлама алу хокукы сакланып калырга мөмкин.

Хакимиятнен җирле органнарына табышка салымның җирле бюджетларга күчерелүче өлешендә шундый ук карарлар кабул итүне тәкъдим итәргә.

13 статья. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына предприятиеләрнең һәм оешмаларның салымнар, җыемнар һәм исәпләнгән пеняләр, шулай ук Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының реструктурлаштыру турында карар кабул итү көненә гамәлдә булган салым законнары кысаларындагы салым законнарын бозган өчен салынган штрафлар буенча Татарстан Республикасының республика бюджетына түләнергә тиешле бурычларын реструктурлаштыру хокукын бирергә.

Реструктурлаштыру уздыруның шартлары һәм вакытлары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фондын, Мәдәният үсешенә ярдәм итү фондын һәм Татарстан Республикасы Президентының Резерв фондын Татарстан Республикасының республика бюджетына һәм җирле бюджетларына алына торган салымнарны түләүдән азат итү хокукын бирергә.

14 статья. 2001 елның 1 гыйнвареннан түбәндәгеләрне бетерергә:

Татарстан Республикасының Эш белән тәэмин итү дәүләт фондын;

Татарстан Республикасында Юллар фондын;

Татарстан Республикасының Минераль ресурс запасларын яңадан торгызу һәм файдалы казылмалар чыгаруның нәтиҗәлелеген арттыру фондын;

Татарстан Республикасының Спирт, аракы-ликер һәм шәраб сәнәгатен үстерү фондын;

Татарстан Республикасы буенча Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар министрлыгы идарәсен үстерү фондын;

Татарстан Республикасы буенча Россия Федерациясенең Федераль салым полициясе хезмәте идарәсен үстерү фондын;

Бөлгенлеккә төшү һәм финанс савыктыру гамәлләрен тәэмин итү махсуслаштырылган фондын.

15 статья. 2001 елга Татарстан Республикасының республика бюджетына түбәндәге фондларны тупларга :

Татарстан Республикасы ЭЭМ Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе идарәсенең Юл хәрәкәте иминлеге фондын;

Татарстан Республикасының Хосусыйлаштыру фондын;

Гомумтармак һәм тармакара фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләренең (НИОКР) республика фондын;

Мәҗбүри медицина иминияте фондын;

Шәһәрләрне, районнарны һәм авылларны газлаштыру буенча дәүләт бюджет фондын;

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фондын;

Татарстан Республикасының «Янгын куркынычсызлыгы» дәүләт максатчан бюджет фондын;

Кече эшкуарлыкка финанс ярдәме күрсәтү Татар республика фондын;

Татарстан Республикасының Экология фондын.

16 статья. 2001 елга Татарстан Республикасының республика бюджетында төп чыганаклар буенча керемнәрнең килерен түбәндәге суммаларда исәпләргә:

(мең сумнарда)

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Салым керемнәре - барлыгы, шул исәптән: | 14033461 |
| | - предприятиеләр һәм оешмалар табышына (керемнәренә) салым | 5598852 |
| | - физик затлардан керем салымы | 992508 |
| | - акцизлар | 976000 |
| | - сатудан салым | 340000 |
| | - предприятиеләр мөлкәтенә салым | 544344 |
| | - жир салымы һәм жир өчен аренда хакы | 319060 |
| | - чит ил акча берәмлекләрен, чит ил валютасында белдерелгән түләү документларын сатып алуга салым | 14000 |
| | - автомобиль юлларыннан файдаланучыларга салым | 1603542 |
| | - транспорт чаралары хужаларыннан салым | 102529 |
| | - минерал-чимал базасын торгызуга түләүләр | 2200000 |
| | - табигый ресурслардан файдаланган өчен түләүләр | 1339026 |
| | - башка салымнар, җыемнар һәм пошлиналар | 3600 |
| 2. | Салымга карамаган керемнәр - барлыгы, шул исәптән: | 289961 |
| | - дәүләт милкендәге мөлкәттән яки эшчәнлектән килгән керемнәр | 36419 |
| | - салымга карамаган башка керемнәр, штрафлар. зыян каплау | 253542 |
| 3. | Максатчан дәүләт фондлары керемнәре - барлыгы, шул исәптән: | 5892636 |
| | Татарстан Республикасы ЭЭМ ЮХИДИ идарәсенең Юл хәрәкәте иминлеге фонды | 138000 |
| | Татарстан Республикасынын Хосусыйлаштыру фонды | 360000 |
| | Гомумтармак һәм тармакара фәнни-тикшеренү һәм тәжрибә-конструкторлык эшләре (НИОКР) фонды | 185000 |
| | Мәжбүри медицина иминияте | 2271921 |
| | Татарстан Республикасының «Янгын куркынычсызлыгы» дәүләт максатчан бюджет фонды | 100000 |
| | Татарстан Республикасының Экология фонды | 337715 |
| | Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды | 2500000 |
| | 4. Федераль компенсацияләр фондыннан субвенцияләр | 708151 |

17 статья. 2001 елда Татарстан Республикасы дәүләт бурычының иң чик күләмен 6800000 мең сум, шул исәптән дәүләт гарантияләре буенча йөкләмәләрнең иң чик күләмен 2900000 мең сум итеп билгеләргә.

Татарстан Республикасының 2001 елда бирелә торган дәүләт гарантияләренең күләмен 900000 мең сумнан артмаган суммада билгеләргә.

18 статья. Халык депутатларының җирле Советлары 2001 елга үз бюджетларын төзегәндә, сатудан салымның бер өлешен, физик затлар мөлкәтенә салымның бер өлешен, физик затлардан керем салымының бер өлешен, җир өчен салымның һәм аренда түләвенең районнар һәм шәһәрләр бюджетларына күчерелергә тиешле бер өлешен, җирле үзидарә органнары тарафыннан каралган чыгымнарны каплар өчен җитәрлек күләмнәрдә җирле үзидарәләрнең бюджетларына тапшырырга тиеш.

Әгәр югарыда күрсәтелгән чыганаклардан керә торган акчалар суммасы минималь социаль стандартлардан һәм нормалардан кимрәк булса, халык депутатларының җирле Советларына үз бюджетларында җирле үзидарә органнарына дотацияләр һәм субвенцияләр бүлеп бирүне тәкъдим итәргә.

19 статья. 2001 елда районнар һәм шәһәрләр бюджетларына салымнар түбәндәге күләмнәрдә исәпләнә дип билгеләргә:

- предприятиеләрнең һәм оешмаларның табышына (керемнәренә) салым салынучы табышның 19 проценты күләмендә: Баулы районына һәм шәһәренә — 3 процент, Бөгелмә районына һәм шәһәренә — 3 процент, Алабуга районына һәм шәһәренә — 18 процент, Зәй районына һәм шәһәренә — 5 процент, Лениногорск районына һәм шәһәренә — 2 процент, Нурлат районына һәм шәһәренә — 6 процент, Түбән Кама районына һәм шәһәренә — 1 процент, Казан шәһәренә — 10 процент. Предприятиеләр һәм оешмалар табышына (керемнәренә) салым Азнакай районы һәм шәһәре, Әлмәт районы һәм шәһәре, Сарман районы бюджетларына салым салына торган табышның 19 проценты күләмендә күчерелми.

Арадашчылык гамәлләреннән һәм алыш-биреш итүләрдән, биржалардан, брокер конторалрыннан, банклардан, башка кредит һәм иминләштерү оешмаларыннан алынган табышка салымны, видеосалоннардан, язмалы җайланмалар һәм алардагы язмалар прокатыннан алынган салымнарны салым салына торган табыштан 19 процентлы ставка өчен билгеләнгән нормативларга пропорциональ рәвештә бүләргә:

- Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән минималь ставкадан күбрәк исәпләнгән салым суммасының 50 проценты күләмендә уен бизнесына салым;

- физик затлар керемнәренә салымның гомуми суммасыннан 84 процент күләмендә, ә түбәндәге районнарда һәм шәһәрләрдә әлеге салым түбәндә санап кителгән процентларда, күрсәтелгән районнар

һәм шәһәрләр территорияләрендәге физик затларның керемнәренә салымның гомуми суммасыннан 84 проценттан алып:

Азнакай районына һәм шәһәренә – 56 процент, Баулы районына һәм шәһәренә – 65 процент, Зәй районына һәм шәһәренә – 36 процент, Лениногорск районына һәм шәһәренә – 97 процент, Сарман районына – 23 процент, Әлмәт районына һәм шәһәренә – 30 процент.

Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетына физик затлар кеременнән алынучы салымның гомуми суммасыннан унбиш проценты Татарстан Республикасының республика бюджетында туплана һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган гомумреспублика максатчан программаларын, шулай ук "Ветераннар турында", "Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында" , "Балалары булган гражданнарга дәүләт пособиеләре турында" федераль законнарны өлешчә финанслауга юнәлдерелә.

- предприятиеләр мөлкәтенә салым, түбәндәгеләрдән тыш, 100 процент күләмендә:

Азнакай районына һәм шәһәренә – 40 процент, Әлмәт районына һәм шәһәренә – 10 процент, Баулы районына һәм шәһәренә – 72 процент, Бөгелмә районына һәм шәһәренә – 65 процент, Алабуга районына һәм шәһәренә – 98 процент, Зәй районына һәм шәһәренә – 45 процент, Лениногорск районына һәм шәһәренә – 30 процент, Нурлат районына һәм шәһәренә – 61 процент, Сарман районына – 50 процент, Түбән Кама районына һәм шәһәренә – 86 процент, Казан шәһәренә – 98 процент;

- эшчәнлекнең аерым төрләре өчен оешмалар тарафыннан Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетына күчерелергә тиешле салымның гомуми суммасыннан 50 процент күләмендә бердәм салым;

- кече эшкуарлык субъектлары – оешмалар өчен Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетына күчерелергә тиешле салым суммасыннан табышка салым нормативлары буенча алына торган барлык табышка бердәм салым;

- Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетына күчерелергә тиешле суммадан 50 процент күләмендә җиргә салым һәм җир өчен аренда хакы.

Авыл торак пунктлары чикләре кысаларындагы җирләр һәм алар карамагына бирелгән җирләр өчен түләүләр җирле үзидарә бюджетларына күчерелә.

<u>20 статья.</u> Нефть чыгаручы компанияләрне, бораулаганнан соң үзләштерүне көткән яна скважиналардан гайре, контрольдәге эшләми торган скважиналарны һәм 1999 елның 1 гыйнварена консервациядә булган скважиналарны файдалануга тапшырудан чыгарылган 1695 мең тонна нефтькә карата Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетына җир асты

байлыкларыннан файдаланган өчен түләүдән һәм минераль ресурслар запасын янадан торгызу өчен акча күчерүләрдән азат итәргә.

21 статья. Россия Федерациясе Салым кодексының беренче бүлегендәге 116, 117, 118, 124, 125, 126, 128, 129, 129-1, 132, 134 һәм 135-1 статьяларының, шулай ук 120 статьяның 1 һәм 2 пунктларында каралган салым санкцияләре буларак кулланыла торган түләүләр (штрафлар) суммасының 25 проценты - Татарстан Республикасының республика бюджетына, 25 проценты районнар һәм шәһәрләр бюджетларына күчерелә.

22 статья. 2001 елга Татарстан Республикасының республика бюджетында чыгымнарны финанслауга ассигнованиеләрнең гомуми күләмен 22565560 мең сум, шул исәптән агымдагы чыгымнар бюджетын 13555611 мең сум, үсеш бюджетын 9009949 мең сум итеп билгеләргә һәм аларны бюджет чыгымнарының функциональ классификациясе бүлекләре һәм бүлекчәләренә түбәндәге суммаларда җибәрергә:

(мең сумнарда)

| Бүлек һәм бүлекчәнең коды | | Барлыгы | Шул исәптән | |
|---|---|---|---|---|
| | | | үсеш бюджеты | компенсацияләрнең федераль фондыннан субвенцияләр |
| | 1. Дәүләт хакимияте һәм идарәсенә, шул исәптән: | 485336 | | |
| 0101 | - Татарстан Республикасы Президенты эшчәнлегенә | 36558 | | |
| 0102 | - дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органнары эшчәнлегенә | 38134 | | |
| 0103 | - дәүләт хакимиятенең башкарма органнары эшчәнлегенә | 396134 | | |

| | | |
|---|---|---|
| 0105 | - гомумдәүләт идарәсенең башка чыгымнары | 14510 |
| | дәүләт заказы бүлеге буенча чыгымнарның гомуми суммасы | 7590 |
| | 2. Суд хакимиятенә, шул исәптән: | 26041 |
| 3004 | - Татарстан Республикасы Югары арбитраж судына | 18581 |
| 3004 | - Татарстан Республикасы Конституция судына | 5921 |
| 0201 | - Дәүләт нотариаль конторaларына | 1539 |
| | дәүләт заказы бүлеге буенча чыгымнарнын гомуми суммасы | 4089 |
| 0103 | 3.Халыкара эшчәнлеккә | 34023 |
| 0501, 0509 | 4. Хокук саклау эшчәнлегенә, | 510000 |
| | шул исәптән: - алкогольле продукция житештерү һәм анын әйләнеше өлкәсендә хокук бозуларны ачу һәм булдырмый калу, житештерүче предприятиеләрне һәм эшкуарларны криминаль структуралардан яклау буенча Татарстан Республикасы ЭЭМ каршындагы милиция бүлекчәсен финанслауга чыгымнар | 10000 |
| | дәүләт заказы бүлеге буенча чыгымнарнын гомуми суммасы | 5000 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 0601, 0602 | 5. Фундаменталь тикшеренүләр һәм фәнни-техник прогресска ярдәм итү | 46043 | 46043 |
| | дәүләт заказы бүлеге буенча чыгымнарның гомуми суммасы | 1490 | |
| | 6. Сәнәгагә, энергетикага, төзелешкә, шул исәптән: | 34969 | |
| 0705 | - ягулык-энергетика комплексына | 27969 | |
| 0707 | - төзелешкә, архитектурага | 7000 | |
| | 7. Авыл хуҗалыгына, | 2350699 | 500000 |
| | шул исәптән: | | |
| 0800, 0801 | - авыл хуҗалыгы җитештерүенә, | 1936560 | 500000 |
| | шулардан ветеринариягә | 86560 | |
| 0802 | - җир ресурсларына, | 319060 | |
| | шулардан җирләрне тамырдан яхшыртуга, | 276000 | |
| | шул исәптән: | | |
| | - әче туфракка известь кертүгә | 183000 | |
| | - органика чыгаруга һәм кертүгә | 50000 | |
| | - су сиптерү сезонына сугару системаларын әзерләүгә һәм эксплуатацияләүгә | 30000 | |
| | - күпъеллык үсентеләр әзерләүгә | 13000 | |
| 0805 | - авыл хуҗалыгы өлкәсендәге башка гамәлләргә | 95 079 | |
| | дәүләт заказы бүлеге буенча чыгымнарның гомуми суммасы | 505000 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | 8. Әйләнә-тирә мохитне, табигый байлыкларны саклауга, гидрометеорологиягә, картографиягә һәм геодезиягә, | 140960 | | |
| | шул исәптән: | | | |
| 0900, 0902 | - урман ресурсларына | 119200 | | |
| 0904 | -гидрометеорологиягә | 1 160 | | |
| 0900, 0906 | -әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге башка чыгымнарга | 20600 | | |
| | дәүләт заказы бүлеге буенча чыгымнарның гомуми суммасы | 8650 | | |
| | 9. Транспортка, шул исәптән: | 2091151 | 1756071 | 15853 |
| 1000, 1001 | - автомобиль транспортына | 241530 | | 14104 |
| 1005 | - тимер юл транспортына | 62567 | | 1178 |
| 1005 | - һава транспортына | 12283 | | 232 |
| 1004 | - су транспортына | 18700 | | 339 |
| 1000, 1006 | - юл хуҗалыгына | 1756071 | 1756071 | |
| | 10.Торак-коммуналь хуҗалыгына, | 384425 | | 26608 |
| | шул исәптән: | | | |
| 1200, 1201 | - торак хуҗалыгына (торак фондын һәм социаль-мәдәни өлкә объектларын кабул итүне һәм файдалануга тапшыруны кертеп) | 153700 | | |
| 1202 | - коммуналь хуҗалыкка | 219749 | | 26608 |
| 1203 | - коммуналь хуҗалыкның башка структураларына | 10976 | | |

| | | |
|---|---|---|
| | дәүләт заказы бүлеге буенча чыгымнарның гомуми суммасы | 66662 |
| | 11. Гадәттән тыш хәлләрне һәм табигый бәла-казаларны кисәтүгә һәм бетерүгә, | 25680 |
| | шул исәптән: | |
| 1302 | - гадәттән тыш хәлләрне кисәтүгә һәм бетерүгә | 4000 |
| 1303 | - граждан оборонасына | 21680 |
| | дәүләт заказы бүлеге буенча чыгымнарның гомуми суммасы | 180 |
| | 12. Мәгарифкә, шул исәптән: | 324632 |
| 1402 | - гомуми белем бирүгә, шул исәптән гомуми белем бирү учреждениеләре өчен спорт инвентарьлары сатып алуга | 30053<br>10000 |
| 1404 | - урта һөнәр белеме бирүгә | 108692 |
| 1405 | - кадрларны кабат әзерләүгә һәм квалификацияләрен күтәрүгә | 21 436 |
| 1406 | - югары һөнәр белеме бирүгә | 31 269 |
| 1407 | -мәгариф өлкәсендәге башка чыгымнарга | 133182 |
| | дәүләт заказы бүлеге буенча чыгымнарның гомуми суммасы | 17000 |
| | 13.Мәдәнияткә, сәнгатькә һәм кинематографиягә, | 294651 |
| | шул исәптән: | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1501 | - мәдәнияткә һәм сәнгатькә, | 276211 | |
| | шул исәптән: | | |
| | - авыл мәдәният учреждениеләренең матди-техник базасын ныгытуга чыгымнар | 5000 | |
| | - Татарстан Республикасының һәрьеллык елъязмалары брошюраларын бастырып чыгаруга | 300 | |
| 1502 | - кинематографиягә | 18440 | |
| | дәүләт заказы бүлеге буенча чыгымнарның гомуми суммасы | 3750 | |
| тиешле бүлекчәләр буенча | 14. "Татарстан Республикасы халыкларының телләре турында" Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыруга | 8100 | 8100 |
| | 15. Массакүләм мәгълүмат чараларына, шул исәптән: | 131076 | |
| 1601 | - телевидениегә һәм радиотапшыруларга | 65 283 | |
| 1602 | - көндәлек матбугатка һәм нәшриятларга | 62953 | |
| 1602 | - башка массакүләм мәгълүмат чараларына | 2840 | |
| | дәүләт заказы бүлеге буенча чыгымнарның гомуми суммасы | 1200 | |
| тиешле бүлекчәләр буенча | 16."Латин графикасы нигезендә татар алфавитын торгызу турында" Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыруга | 26 531 | 26 531 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | 17. Сәламәтлек саклауга һәм физик культурага, | 1410175 | | |
| | шул исәптән: | | | |
| 1701 | - сәламәтлек саклауга | 1141221 | | |
| 1702 | -санитария-эпидемиология күзәтчелегенә | 113 758 | | |
| 1703, 1405 | - физик культурага һәм спортка, | 155 196 | | |
| | шул исәптән: | | | |
| 1405 | - балалар һәм яшүсмерләр арасында физкультура-спорт эшен үстерүгә | 60 000 | | |
| | дәүләт заказы бүлеге буенча чыгымнарның гомуми суммасы | 323 000 | | |
| | 18. Социаль сәясәткә, | 885163 | 10 000 | 540079 |
| | шул исәптән: | | | |
| 1801 | - социаль тәэминат учреждениеләренә | 140 041 | | |
| 1802 | -социаль ярдәм күрсәтүгә | 81417 | | 24000 |
| 1803 | -яшьләр сәясәтенә | 25 926 | 10 000 | |
| тиешле бүлекчәләр буенча | шулардан “Татарстан балалары” программасына | 10 000 | 10 000 | |
| 1806 | -социаль сәясәт өлкәсендәге башка гамәлләргә, | 637779 | | 516079 |
| | шул исәптән: халыкны эш белән тәэмин итү программасын гамәлгә ашыруга | 67600 | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | дәүләт заказы бүлеге буенча чыгымнарның гомуми суммасы | 1 413 | | |
| тиешле бүлекчәләр буенча | 19. 1999-2001 елларга Татарстан Республикасында наркотик чараларны кирәгеннән артык куллануга һәм аларның законсыз әйләнешенә каршы комплекслы республика программасын гамәлгә ашыруга | 50 000 | 50 000 | |
| 1900 | 20.Дәүләт бурычын түләүгә | 634363 | | |
| | 21.Башка дәрәжәләрдәге бюджетларга финанс ярдәме күрсәтүгә,<br><br>шулардан: | 3313775 | | 125611 |
| 3201 | -район һәм шәһәр бюджетларын дотацияләүгә | 1041576 | | |
| 3202 | -бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә бердәй социаль салым түләүне исәпкә алып, хезмәт хакы түләү өчен район һәм шәһәр бюджетларына субвенцияләр | 1743450 | | |
| 3202 | - компенсацияләрнең федераль фондыннан субвенцияләр | 125611 | | 125611 |
| 3203 | - «Ветераннар турында» Федераль законны өлешчә финанслауга район һәм шәһәр бюджетларына субвенцияләр | 403138 | | |
| | 22.Башка чыгымнар, шул исәптән: | 175 131 | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 3001 | -Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фондына | 100 000 | |
| 3004 | -Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясен тотуга | 1 982 | |
| 3002 | - Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны уздыруга | 19 916 | |
| 3002 | - Татарстан Республикасы халык депутатларының һәм Татарстан Республикасы халык депутатларының жирле Советлары халык депутатларының киткәннәре урынына яңаларын сайлауларны уздыруга | 1 000 | |
| 3004 | - "Зур Идел" Идел буе республикалары һәм өлкәләренең икътисадый хезмәттәшлеге ассоциациясенә Татарстан Республикасының әгъзалык взнослары | 530 | |
| 3004 | -2002 елда Бөтенроссия халык санын алуга әзерлек эшләре алып баруга | 520 | |
| 3004 | - башка чыгымнарга | 51 183 | |
| тиешле бүлекчәләр буенча | 23.Дәүләт капитал салуларына | 750 000 | 750 000 |
| | дәүләт заказы бүлеге буенча чыгымнарның гомуми суммасы | 23 351 | 23 351 |
| 1200 | 24.Газлаштыру программасын гамәлгә ашыруга | 250 000 | 250 000 |
| | дәүләт заказы бүлеге буенча чыгымнарның гомуми суммасы | 50 000 | 50 000 |

68

| | | | |
|---|---|---|---|
| 0700 | 25. Спирт сәнәгасен үстерүгә | 90000 | 90000 |
| 3000 | 26. Минерал-чимал базасын торгызуны финанслауга | 2200000 | 2200000 |
| | 27.Максатчыл бюджет фондлары чыгымнарына, барысы шул исәптән: | 5892636 | 3323204 |
| 3130 | Татарстан Республикасы ЭЭМ ЮХИДИ идарәсенең Юл хәрәкәте иминлеге фондына | 138 000 | 30 930 |
| 3130 | - Татарстан Республикасының Хосусыйлаштыру фондына | 360 000 | 323 644 |
| 3130 | -Гомумтармак һәм тармакара фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләренен (НИОКР) республика фондына | 185 000 | 167600 |
| 3130 | -Мәҗбүри медицина иминиятенә | 2271921 | |
| 3130 | - Татарстан Республикасының «Янгын куркынычсызлыгы» максатчыл дәүләт бюджет фондына | 100000 | 58310 |
| 3130 | - Татарстан Республикасынын Экологик фондына | 337715 | 251720 |
| 3130 | - Татарстан Республикасы Президенты каршындагы дәүләт торак фондына | 2500000 | 2491000 |

23 статья. 2001 елга авыл хуҗалыгы өчен бюджет акчаларын бүлүне әлеге Законның 1 нче, 2 нче кушымталары нигезендә расларга.

69

24 статья. 2001 елга дәүләт хакимиятен гамәлгә ашыру өчен чыгымнарны 485336 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән:

түбәндәгеләрнең эшчәнлеген финанслау өчен чыгымнар:

| | (мең сумнарда) |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Президенты Аппараты эшчәнлегенә | 36558 |
| Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, аның Аппаратының, даими нигездә эшләүче халык депутатлары эшчәнлегенә | 31891 |
| Татарстан Республикасы халык депутатларына депутат вәкаләтләрен башкаруга бәйле чыгымнарны түләүгә | 546 |
| Закон проектларын эшләүгә һәм аларны экспертизалауга бәйле чыгымнарга | 1000 |
| Татарстан Республикасы Дәүләт Советы сессияләрен уткәрүгә бәйле чыгымнарга | 1726 |
| Татарстан Республикасы Дәүләт Советынын Парламент контроле комитеты эшчәнлегенә | 2971 |
| Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты эшчәнлегенә | 25837 |
| Татарстан Республикасы министрлыклары, дәүләт комитетлары, ведомстволары һәм аларның органнары эшчәнлегенә | 343297 |
| “Дәүләт хезмәте турында” Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чыгымнарына | 23000 |
| “Татарстан Республикасы алдында аерым казанышлары булган гражданнарның дәүләт пенсияләренә өстәмә түләү турында” Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чыгымнарына | 4000 |
| Архив учреждениеләрен финанслау чыгымнарына | 11570 |

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил һәм аның аппараты эшчәнлеген финанслау чыгымнарына | 2940 |

25 статья. Түбәндәгеләрне тотуга чыгымнарны 34023 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән:

Россия Федерациясе субъектларында Татарстан Республикасы вәкиллекләрен тотуга 2001 елга чыгымнарны 12739 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән:

(мең сумнарда)

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасының Россия Федерациясендәге вәкаләтле вәкиллегенә | 10169 |
| Татарстан Республикасының Свердлов өлкәсендәге даими вәкиллегенә | 1224 |
| Татарстан Республикасының Санкт-Петербург шәһәрендәге һәм Ленинград өлкәсендәге даими вәкиллегенә | 1346 |

Татарстан Республикасының халыкара эшчәнлеген башкару өчен 2001 елга чыгымнарны 21284 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән:

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасының Үзбәкстан Республикасындагы даими вәкиллегенә | 1321 |
| Татарстан Республикасының Әзәрбайҗан Республикасындагы даими вәкиллегенә | 1596 |
| Татарстан Республикасының Казахстан Республикасындагы вәкаләтле вәкиллегенә | 1108 |
| Татарстан Республикасының Франциядәге вәкаләтле вәкиллегенә | 5319 |
| Татарстан Республикасының Төркиядәге вәкаләтле вәкиллегенә | 3393 |
| Татарстан Республикасының Вашингтон шәһәрендәге (АКШ) даими вәкиллегенә | 3702 |
| Татарстан Республикасының Чехия һәм Словакия Республикаларындагы даими вәкиллегенә | 2178 |

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасының Кипр Республикасындагы вәкиллегенә | 1671 |
| Татарстан Республикасының Финляндия Республикасындагы сәүдә-икътисад буенча вәкиленә | 996 |

26 статья. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетынын 2001 елда дәүләт хезмәткәрләренең һәм бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең санын арттыруга китерүче карарлар кабул итәргә хокукы юк, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары буенча гамәлгә кертелүче яңа объектлардагыларның санын билгеләү моңа керми.

Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең жирле органнарына 2001 елда бюджет дәүләт хезмәткәрләренен һәм бюджет өлкәсе хезмәткәрләренен санын арттыруга китерүче карарлар кабул итмәскә дигән тәкъдим ясарга.

27 статья. 2001 елда Татарстан Республикасының дәүләт хезмәткәрләрен тотуга чыгымнарны экономияләү максатында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы дәүләт хезмәткәрләренең иң чик санынраслауны да кертеп, Татарстан Республикасының башкарма хакимияте органнары структурасын оптимальләштерү чараларын күрергә тиеш.

28 статья. Бюджетта каралган гамәлләрне өзлексез финанслауны тәэмин итү максатларында, 2001 елда Татарстан Республикасынын республика бюджетыннан район һәм шәһәр бюджетларына 3313775 мең сум күләмендә дотацияләр һәм субвенцияләр бүлеп бирергә, шул исәптән:

(мең сумнарда)

| Районнар һәм шәһәрләр исемлеге | Дотация | Бердәй социаль салым түләвен исәпкә алып, бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә, хезмәт хакын өлешчә түләүгә субвенция | «Ветераннар турында» Федераль законны өлешчә финанслауга субвенция | Компенсацияләр нең федераль фондыннан субвенция |
|---|---|---|---|---|
| Әгерже районы | 19 203 | 56 160 | 542 | 165 |
| Азнакай районы һәм шәһәре | - | - | 3297 | 1012 |
| Аксубай районы | 7 895 | 30 211 | 326 | 99 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Актаныш районы | 32 035 | 53 126 | 286 | 86 |
| Алексеевск районы | 44 948 | 48 125 | 293 | 88 |
| Әлки районы | 44 896 | 42 259 | 186 | 56 |
| Әлмәт районы һәм шәһәре | - | - | 18982 | 5932 |
| Апас районы | 27 948 | 41 069 | 176 | 53 |
| Арча районы | 60 201 | 70 915 | 1421 | 442 |
| Әтнә районы | 21 865 | 23 088 | 130 | 39 |
| Баулы районы һәм шәһәре | - | - | 2828 | 882 |
| Балтач районы | 45 561 | 53 597 | 529 | 161 |
| Бөгелмә районы һәм шәһәре | - | - | 7248 | 2223 |
| Буа районы һәм шәһәре | 28 323 | 70 838 | 903 | 279 |
| Югары Ослан районы | 18 135 | 33 341 | 165 | 50 |
| Биектау районы | 6 604 | 24 450 | 524 | 159 |
| Чүпрәле районы | 29 810 | 44 582 | 280 | 87 |
| Алабуга районы һәм шәһәре | - | - | 5777 | 1793 |
| Зәй районы һәм шәһәре | - | - | 2775 | 857 |
| Зеленодольск районы һәм шәһәре | 43 175 | 168202 | 13353 | 4118 |
| Кайбыч районы | 14 873 | 25 421 | 61 | 19 |
| Кама Тамагы районы | 35 952 | 29 856 | 180 | 54 |
| Кукмара районы | 66 117 | 74 410 | 1131 | 350 |
| Лаеш районы | 14 096 | 49 843 | 381 | 115 |
| Лениногорск районы һәм шәһәре | - | - | 4974 | 1546 |
| Мамадыш районы | 68 824 | 76 771 | 905 | 281 |
| Менделеев районы | 7 724 | 29 600 | 1334 | 407 |
| Минзәлә районы | 59 190 | 45 475 | 571 | 177 |
| Мөслим районы | 31 434 | 38 918 | 212 | 65 |
| Түбән Кама районы һәм шәһәре | - | - | 24622 | 7692 |
| Яна Чишмә районы | 1 927 | 2 500 | 90 | 27 |
| Нурлат районы һәм шәһәре | - | - | 1016 | 310 |
| Питрәч районы | 34 139 | 44 592 | 156 | 47 |
| Балык Бистәсе районы | 25 887 | 53 597 | 313 | 95 |
| Саба районы | 44 130 | 47 482 | 382 | 117 |
| Сарман районы | - | - | 971 | 293 |
| Спас районы | 37 134 | 45 082 | 316 | 96 |
| Тәтеш районы | 16 571 | 65 880 | 646 | 198 |
| Тукай районы | - | - | 386 | 116 |
| Теләче районы | 26 528 | 27 974 | 83 | 24 |
| Чирмешән районы | 3 462 | 12 700 | 228 | 69 |
| Чистай районы һәм шәһәре | 73 115 | 115 286 | 4268 | 1329 |
| Ютазы районы | 1 106 | 3 200 | 440 | 133 |
| Яр Чаллы шәһәре | 48 768 | 194 900 | 57327 | 17888 |
| Казан шәһәре | - | - | 242124 | 75582 |
| Барлыгы: | 1041576 | 1 743 450 | 403138 | 125611 |

Дотация Татарстан Республикасы республика бюджетының керем өлеше фактта үтәлүен исәпкә алып бүленә.

Татарстан Республикасының республика бюджетыннан субвенция, бердәй социаль салым түләвен исәпкә алып, бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт хакын өлешчә түләү өчен, «Ветераннар турында» Федераль законны өлешчә финанслау өчен бирелә һәм катгый рәвештә бары тик максатчыл билгеләнештә генә файдаланыла.

29 статья. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты 2001 елда түбәндәгеләр буенча финанслауны хәл итәргә тиеш: гомумфедераль законнарга күчкәндә Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетыннан югалтуларны компенсацияләү өлешендә федераль бюджеттан финанс ярдәменең барлык төрләре исәбеннән һәм кире кайтару шарты белән элек бирелгән кредитларны кире кайтарудан, алардан файдаланган өчен түләүне дә кертеп, Татарстан Республикасының республика бюджетына керүче акчалар исәбеннән дәүләт бурычын түләү; районнарны, шәһәрләрне һәм авыл торак пунктларын газлаштыру; Казан халыкара аэропортын һәм Казан шәһәренең тарихи үзәген реконструкцияләүне, Кама елгасы аша күпер төзелешен дә кертеп, капитал салулар; азык-төлек товарлары буенча дәүләт заказын формалаштыру өчен кредит (кире кайтару шарты белән) бирү; муниципаль милициянең матди-техник базасын ныгыту.

30 статья. 2001 елда Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгы ЮХИДИ идарәсенең Юл хәрәкәте иминлеге фондына (алга таба - Юл хәрәкәте иминлеге фонды) кертелүче штрафларның күләмнәрен - Россия Федерациясе законнары нигезендә, ә Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгы ЮХИДИ идарәсенең Юл хәрәкәте иминлеге фондына автотранспорт чараларына дәүләт техник тикшерүе уздырудан керүче җыемнарның һәм дәүләт теркәү тамгалары биргән өчен алынган җыемнарның ставкаларын законнар нигезендә билгеләргә.

2001 елга Юл хәрәкәте иминлеге фонды бюджетын керемнәр буенча - 138000 мең сум, чыгымнар буенча 138 000 мең сум күләмендә расларга.

2001 елда Юл хәрәкәте иминлеге фондының бюджет керемнәре түбәндәге чыганаклар исәбеннән туплана:

(мең сумнарда)

| | |
|---|---|
| Штрафлар | 60 000 |
| Автотранспорт чараларына дәүләт техник тикшерүе уздырудан җыемнар | 42 000 |
| Дәүләт теркәү тамгалары биргән өчен җыемнар | 18000 |
| Башка чыгымнар | 18000 |

2001 елда Юл хәрәкәте иминлеге фонды акчалары түбәндәге максатларга җибәрелә:

| | (мең сумнарда) |
|---|---|
| Юл хәрәкәте иминлеге фондының шәһәр һәм район бүлекчәләренә бүлеп бирелүче суммаларга | 22076 |
| Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү гамәлләренә | 22077 |
| Дәүләт техник тикшерү станцияләрен арттыруга һәм тотуга бүлеп бирелүче суммаларга | 30930 |
| Дәүләт теркәү тамгалары чыгару буенча эксплуатация чыгымнары өчен бүлеп бирелүче суммаларга | 13223 |
| Татарстан Республикасы Президентының Резерв фондына бүлеп бирелүче суммаларга | 6900 |
| Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгына бүлеп бирелүче суммаларга | 6900 |
| Заем акчаларын түләүгә | 21500 |
| Башка чыгымнарга | 14394 |

<u>31 статья.</u> 2001 елга Татарстан Республикасының Хосусыйлаштыру фонды (алга таба - Хосусыйлаштыру фонды) бюджетын керемнәр буенча - 360000 мең сум, чыгымнар буенча 360000 мең сум күләмендә расларга.

2001 елда Хосусыйлаштыру фонды бюджеты керемнәре түбәндәге чыганаклар исәбеннән туплана:

| | (мең сумнарда) |
|---|---|
| Мөлкәт сатудан керемнәр | 11520 |
| Хезмәт коллективлары сатып алган акцияләрдән керемнәр | 19047 |
| Кыйммәтле кәгазьләр сатудан керемнәр (акцияләрнең дәүләт өлеше) | 22500 |
| Дәүләт мөлкәтен арендага бирүдән керемнәр | 11880 |
| Дәүләт акцияләр пакетына дивидендлардан керемнәр | 261232 |
| Элек бирелгән кредитларны кайтару | 33700 |
| Башка керемнәр | 121 |

2001 елда Хосусыйлаштыру фонды акчалары түбәндәге максатларга юнәлдерелә:

(мең сумнарда)

| | |
|---|---|
| Инвестиция программаларын һәм проектларын финанслауга һәм республика предприятиеләренең хупланган инвестиция проектлары буенча коммерция банклары кредитларына процент ставкасының бер өлешен компенсацияләүгә, | 193180 |
| шул исәптән: | |
| - "Татарстан Республикасында энергияне сак тоту буенча 2000-2005 елларга республика программасын финанслауга | 108000 |
| Депозитар хезмәт күрсәтүләр өчен түләүгә | 3000 |
| Татарстан Республикасы Президентының Резерв фондына бүлеп бирелүче суммаларга | 18000 |
| Татарстан Республикасының Дәүләт мөлкәтенә идарә буенча дәүләт комитетының гамәлдән чыгарылган шартнамәләре буенча акчаларны кире кайтару чыгымнарына | 3814 |
| Устав һәм эксперт эшчәнлеген финанслауга | 1000 |
| Коммуналь мөлкәткә идарә буенча комитетлар белән үзара исәп-хисап ясауга | 1500 |
| Акча кертүчеләр һәм акционерлар хокукларын яклау буенча республика иҗтимагый-дәүләт фондына бүлеп бирелүче суммаларга | 122 |
| Бөлгенлеккә төшү һәм финанс яктан савыктыру процедураларын финанслауга | 5000 |
| Кече эшкуарлыкка финанс ярдәме күрсәтүнең республика фондына бүлеп бирелүче суммаларга | 20700 |
| Халык-нәфис промыселларын һәм кәсепләрен саклауга һәм үстерүгә | 1000 |
| Сәнәгать предприятиеләрен лизинглауга | 108764 |
| Башка чыгымнарга | 3920 |

32 статья. 2001 елга НИОКР фондының бюджетын керемнәр буенча - 185000 мең сум, чыгымнар буенча 185000 мең сум күләмендә расларга.

2001 елда НИОКР фонды бюджеты керемнәре түбәндәге чыганаклар исәбеннән туплана:

(мең сумнарда)

| | |
|---|---|
| Үзәкләштерелгән өлешне туплауның исәпләү күләме (ирекле кертем) | 120 000 |
| Кредитларны һәм аларга процентларны кире кайтару | 65 000 |

2001 елда НИОКР фонды акчалары түбәндәге максатларга юнәлдерелә:

(мең сумнарда)

| | |
|---|---|
| Инвестиция программаларын һәм проектларын финанслауга, республика предприятиеләренең хупланган инвестиция проектлары буенча коммерция банклары кредитларына процент ставкасының бер өлешен компенсацияләүгә | 139600 |
| Фәнне өстенлекле юнәлешләрдә үстерү буенча дәүләт программасына | 28000 |
| НИОКР фондының устав һәм фәнни-оештыру эшчәнлеген финанслауга | 4500 |
| Татарстан Республикасы Президентының Резерв фондына бүлеп бирелүче суммаларга | 9250 |
| Башка чыгымнарга | 3650 |

НИОКР фонды акчаларын туплау һәм алардан файдалану тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә, дип билгеләргә.

33 статья. 2001 елга Татарстан Республикасының мәҗбүри медицина иминияте бюджетын керемнәр буенча - 2271921 мен сум, чыгымнар буенча 2 271 921 мең сум күләмендә расларга.

2001 елда мәҗбүри медицина иминияте бюджетының керемнәре түбәндәге чыганаклар исәбеннән туплана:

(мең сумнарда)

| | |
|---|---|
| Бердәй социаль салым (мәҗбүри медицина иминиятенә түләүләр буенча ставка өлешендә) | 1 431 320 |
| Йөкләнгән керемгә бердәй салым (мәҗбүри медицина иминиятенә түләүләр буенча ставка өлешендә) | 10513 |
| Мәҗбүри медицина иминиятенә иминләштерү кертемнәре түләүчеләрнең кичектерелгән бурычларын мобилизацияләү | 68866 |
| Эшләмәүче халык өчен җирле бюджетган мәҗбүри медицина иминиятенә кертемнәр | 761222 |

2001 елда мәҗбүри медицина иминияте акчалары түбәндәге максатларга юнәлдерелә:

(мең сумнарда)

| | |
|---|---|
| Медицина хезмәтләре күрсәтү өчен түләү фондына | 1934154 |
| Территория сырхауханә кассаларын тотуга | 49400 |
| Сәламәтлек саклау буенча аерым гамәлләрне финанслауга, барлыгы | 72836 |

шул исәптән:

| | |
|---|---|
| - нормалашкан иминият запасын туплауга | 41375 |
| Мәҗбүри медицина иминиятенең территория программалары кысаларында сырхауханә кассалары эшчәнлеге финанс шартларын тигезләүгә | 208391 |
| Башка чыгымнарга | 7140 |

Татарстан Республикасы шәһәрләренең һәм районнарының 2001 елга бюджетларын формалаштырганда эшләмәүче затларның мәҗбүри медицина иминиятенә кертемнәре суммасын һәм субсидияләрен дарулар белән тәэмин итүгә каралган өстенлекле ташламаларны тәэмин итүне финанслау буенча тулы күләмдә финансланырга тиешле якланган агымдагы чыгымнарга кертүне дәүләт хакимиятенең җирле органнарына тәкъдим итәргә.

<u>34 статья.</u> 2001 елга «Янгын куркынычсызлыгы» Татарстан Республикасы максатчыл дәүләт бюджет фонды бюджетын керемнәр буенча 100000 мең сум, чыгымнар буенча 100000 мең сум күләмендә расларга.

«Янгын куркынычсызлыгы» Татарстан Республикасы максатчыл дәүләт бюджет фонды бюджеты керемнәре 2001 елда түбәндәге чыганаклар исәбеннән тезелә:

(мең сумнарда)

| | |
|---|---|
| «Янгын куркынычсызлыгы» Татарстан Республикасы максатчыл дәүләт бюджет фондына түләүләр буенча түләүчеләрнең кичектерелгән бурычларын мобилизацияләү | 100000 |

«Янгын куркынычсызлыгы» Татарстан Республикасы максатчыл дәүләт бюджет фонды акчалары 2001 елда түбәндәге максатларга җибәреләчәк:

(мең сумнарда)

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгының янгынга каршы дәүләт хезмәтенең шәһәрләрдәге һәм районнардагы бүлекчәләренә түләүләр | 17900 |
| Янгынга каршы көрәш деполары биналарын капиталь төзү һәм ремонтлау | 17860 |
| Янгынга каршы автотехника, автотранспорт сатып алу | 22550 |
| Янгынга каршы техниканы, автотранспортны тоту, ягулык-майлау материалларын, янгынга каршы техника җайланмаларын, янгынга каршы махсус мөлкәтне сатып алу | 15527,5 |

78

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгының янгынга каршы дәүләт хезмәтен тоту | 9737,5 |
| Татарстан Республикасы Президентының Резерв фондына түләүләр | 5000 |
| Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгына түләүләр | 5000 |
| Башка чыгымнар | 6425 |

35 статья. 2001 елга Татарстан Республикасы Экология фондының бюджетын керемнәр буенча 337715 мең сум, чыгымнар буенча 337715 мең сум, дип расларга.

Татарстан Республикасы Экология фонды бюджетының 2001 елга керемнәре түбәндәге чыганаклар исәбеннән төзелә:

(мең сумнарда)

| | |
|---|---|
| Хайваннар дөньясы объектларыннан файдаланган өчен түләү | 36 |
| Су объектларыннан файдаланган өчен түләү | 43776 |
| Зарарлы матдәләрне норматив буенча, нормативтан артыграк чыгарып ташлаган һәм чыгарган өчен, калдыкларны урнаштырган өчен һәм әйләнә-тирә мохиткә зарарлы йогынтының башка төрләре өчен түләү | 277943 |
| Башкалар | 15960 |

Татарстан Республикасы Экология фондының бюджет акчалары 2001 елда түбәндәге максатларга юнәлдереләчәк:

(мең сумнарда)

| | |
|---|---|
| Әйләнә-тирә мохитне саклауның максатчыл программаларын гамәлгә ашыруга | 314170 |
| шул исәптән: | |
| Татарстан Республикасының табигатьне саклау хезмәтләре эшчәнлеген тәэмин итү | 62450 |
| Татарстан Республикасы Президентының Резерв фондына түләүләр | 16685 |
| Башка чыгымнар | 6860 |

36 статья. 2001 елга Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Бюджеттан тыш дәүләт торак фонды бюджетын

керемнәр буенча 2500000 мең сум, чыгымнар буенча 2500000 мен сум күләмендә расларга.

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Бюджеттан тыш дәүләт торак фонды бюджеты керемнәре 2001 елга түбәндәге чыганаклар исәбеннән барлыкка китерелә:

(мең сумнарда)

| | |
|---|---|
| Тузган торакны бетерүгә максатчыл түләүләр | 2500000 |

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Бюджеттан тыш дәүләт торак фонды акчалары түбәндәге максатларга юнәлдерелә:

(мең сумнарда)

| | |
|---|---|
| Яңа торак төзү | 2160000 |
| Төзелеш микрорайоннарында мәгариф һәм социаль-мәдәният-көнкүреш объектларын төзү | 135000 |
| Коммуналь хуҗалык объектларын төзү | 110000 |
| Төзелеш индустриясе базасы гамәлләрен финанслау | 40000 |
| Проект-эзләнү эшләрен финанслау | 26000 |
| Тузган торак фондында яшәүче яшь гаиләләргә кредитлар бирү | 20000 |
| Техник инвентарьлаштыруны оештыру, акчаларны җыю, идарә буенча чыгымнар | 9000 |

37 статья. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Татарстан Республикасының җирле бюджетларына ревизияләр ясарга хокуклы.

38 статья. Дәүләтнеке булмаган яисә муниципаль унитар предприятиеләр, бюджет оешмалары булмаган юридик затларга бюджет кредиты бары тик банк гарантияләре, поручительстволар, мөлкәтне залогка салу бәрабәренә, шул исәптән акцияләр, башка кыйммәтле кәгазьләр, бюджет кредитына исәпләп чыгарылган процентларны кертеп, бирелүче бюджет кредитының 100 процентлы пайлары бәрабәренә бирелергә мөмкин, дип билгеләргә. Бурычлар буенча йөкләмәләрнең үтәлешен тәэмин итү югары дәрәҗәдәге ликвидлыкка ия булырга тиеш.

39 статья. Татарстан Республикасы республика бюджетыннан һәм җирле бюджетлардан элек бирелгән бюджет ссудаларын, бюджет кредитларын кире кайтару исәбеннән килүче акчалар һәм алардан

файдаланган өчен түләүләр Татарстан Республикасының республика бюджетына һәм жирле бюджетларга кертелә, дип билгеләргә.

Бюджет кредитларын кире кайтару, шулай ук алардан файдаланган өчен түләүләр бюджетка кертелүче мәжбүри түләүләргә тиңләштерелә.

40 статья. 2001 елга дәүләтнеке булмаган коммерция оешмаларына Татарстан Республикасының республика бюджетыннан һәм жирле бюджетлардан төзелешкә, объектларны яңадан техник жиһазлауга һәм реконструкцияләүгә акчалар бүлеп бирү, фәкать акцияләрнең номиналь бәясе буенча бүлеп бирелә торган акчалар күләмендә республика һәм муниципаль милеккә тапшырган очракта гына, шулай ук техник-икътисадый нигезләве булганда, кирәкле проект-смета документлары һәм экспертиза бәяләмәләре булганда гына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

41 статья. Дәүләт хакимияте органнарының һәм бюджет учреждениеләренең акча йөкләмәләре буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын түләттерү турында дәгъва мөрәжәгате суд органнарының үтәлеш кәгазьләре нигезендә бурычлыларның Татарстан Республикасы Милли банкында, "Ак Барс" банкында һәм башка вәкаләтле кредит оешмаларында ачылган счетларыннан, шулай ук Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык счетларыннан гамәлгә ашырыла, дип билгеләргә.

Дәүләт хакимияте органнарының һәм бюджет учреждениеләренең Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык счетларыннан түләнергә тиешле акча йөкләмәләре буенча акчаларын түләттерү суд органнары тарафыннан аларга тапшырылган үтәлеш кәгазьләре буенча фәкать Россия Федерациясе бюджетларының ведомство, функциональ һәм икътисадый чыгымнары структурасы нигезендә әлеге Законда каралган максатчыл билгеләнешләр чикләрендә генә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хакимияте органнарының һәм бюджет учреждениеләренең акчаларын суд органнарының үтәлеш кәгазьләре нигезендә гамәлдән чыгару Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы казначылык органнары һәм аның территориаль бүлекчәләре акцепты буенча әлеге статья нигезендә Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы казначылык счетларыннан башкарыла.

Бурычлыларның казначылык счетларында әлеге максатлар өчен житәрлек күләмдә акчалары булмаган очракта, үзенең карамагында шундый бурычлысы булган Татарстан Республикасының бюджет акчалары белән төп эш итүче суд карарларының үтәлеше йөзеннән,

үзенә билгеләнгән ассигнованиеләр кысаларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты урнаштырган тәртиптә субсидар җаваплы була.

42 статья. Суд органнарының Татарстан Республикасы казнасына карата кузгатылган дәгъвалары буенча үтәлеш кәгазьләре Татарстан Республикасының Финанс министрлыгына башкарылу өчен җибәрелә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә аның тарафыннан башкарыла.

Татарстан Республикасы казнасына карата дәгъвалар буенча суд карарларын үтәү Татарстан Республикасының әлеге Законда шушы максатлар өчен каралган ассигнованиеләр исәбеннән гамәлгә ашырыла. Бу чакта суд карарларын әлеге Законда шушы максатларга расланганнан зуррак күләмнәрдә башкару да рөхсәт ителә.

43 статья. Үтәлеше Татарстан Республикасының республика бюджеты һәм җирле бюджетлар акчалары исәбеннән гамәлгә ашырылучы шартнамәләрне дәүләт хакимияте органнарының һәм бюджет учреждениеләренең төзүе һәм алар өчен түләве Россия Федерациясе бюджетларының ведомство, функциональ һәм икътисадый чыгымнары структурасы нигезендә алар өчен расланган бюджет йөкләмәләренең лимитлары чикләрендә башкарыла, дип билгеләргә.

Дәүләт хакимияте органнарының һәм бюджет учреждениеләренең үтәлеше Татарстан Республикасының республика бюджеты һәм җирле бюджетлар акчалары исәбеннән гамәлгә ашырылучы шартнамәләрдә үзләренә расланган бюджет йөкләмәләреннән артыграк кабул ителгән йөкләмәләре агымдагы финанс елындагы Татарстан Республикасының республика бюджеты һәм җирле бюджетлар акчалары исәбеннән түләнергә тиеш түгел.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнары аша Татарстан Республикасының республика бюджеты һәм җирле бюджетлар акчалары исәбеннән башкарылырга тиешле йөкләмәләрне керемнәр һәм чыгымнар сметалары нигезендә исәпкә алуны тәэмин итә. Йөкләмәләрнең исәбен алып бару өчен нигез булган чыгымнарның бюджет классификациясе кодлары (күрсәткечләре) исемлеген Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгели.

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органына исәпкә алу өчен дәүләт хакимияте органнары һәм бюджет учреждениеләре тарафыннан тапшырылган шартнамәләр мәҗбүри рәвештә түбәндәге шартны эченә алырга тиешләр: шартнамә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнарында исәпкә алынган мизгелдән генә үз көченә керә һәм яклар өчен мәҗбүри була (әгәр шартнамәдә яисә башка норматив актта шартнамәнең үз көченә керүенең соңрак вакыты каралмаса).

Татарстан Республикасының республика бюджетын һәм җирле бюджетларны касса буенча үтәү процессында дәүләт хакимияте органнары һәм бюджет учреждениеләре йөкләмәләрне исәпкә алу тәртибе хакында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртипне бозган өчен Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнары аларның чыгымнарын түләүне туктатып торырга хокуклы.

Дәүләт хакимияте органы һәм бюджет учреждениеләре тарафыннан әлеге статья таләпләрен бозып төзелгән шартнамә (яисә аның Татарстан Республикасы бюджетының йөкләмәләрен арттыруны билгеләгән өлеше) югарырак оешма яисә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнары дәгъвасы буенча суд тарафыннан дөрес түгел дип танылырга тиеш.

44 статья. Бюджет учреждениеләре тарафыннан эшкуарлык эшчәнлегеннән һәм керем китерерлек башка төрле эшчәнлектән алынган акчалар Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык счетларында исәпкә алына, дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы Милли банкы, “Ак Барс” банкы һәм башка вәкаләтле банклар Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан ачылган һәм эшкуарлык эшчәнлегеннән һәм керем китерерлек башка төрле эшчәнлектән алынган акчаларны исәпкә алып бару счетларына бушлай хезмәт күрсәтәләр.

Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнары һәм бюджеттан акча алучы башка затлар тарафыннан эшкуарлыктан һәм табыш китерерлек башка төрле эшчәнлектән кергән акчаларны исәпкә алу буенча счетларында калган акчалар хакында Татарстан Республикасы Милли банкыннан, “Ак Барс” банкыннан һәм бүтән вәкаләтле банклардан алынган мәгълүмат нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты 2001 елда күрсәтелгән акчаларга квартал саен мониторинг уздыруны, аларның күләмнәрен һәм кулланылышын ачыклауны гамәлгә ашыра.

45 статья. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты:

- Татарстан Республикасының республика бюджеты акчаларыннан финансланучы оешмаларның, Татарстан Республикасының республика бюджеты акчаларын алучыларның Татарстан Республикасының бюджет законнарында Татарстан Республикасының республика бюджеты акчалары исәбеннән финансланырга рөхсәт ителгән чыгымнарның 1999-2000 елларда бюджет үтәлеше барышында җитәрлек дәрәҗәдә финансланмыйча калуы нәтиҗәсендә 2001 елның 1 гыйнварена җыелган кредиторлык бурычларын тулысынча барлап чыга;

- кредиторлык бурычын тулысынча барлап чыгу нигезендә Татарстан Республикасының республика бюджеты акчаларыннан финансланучы оешмаларның үз эшчәнлекләре барышында бюджет законнары тарафыннан рөхсәт ителмәгән чыгымнарны тотуы

нәтиҗәсендә 2001 елның 1 гыйнварена җыелган бурычларының күләмен билгели;

- Татарстан Республикасының республика бюджетыннан финансланучы оешмаларның ачыкланган кредиторлык бурычларын, шул исәптән реструктурлаштыру юлы белән дә түләттерү механизмнарын, кредит бурычларын реструктурлаштыруның тәртибен һәм вакытларын билгели.

46 статья. Дәүләт идарәсенең җирле органнары гарантиясе (поручительствосы) нигезендә кайтарып алу шарты белән Татарстан Республикасы республика бюджетыннан Татарстан Республикасының дәүләт идарәсе органнарына,предприятиеләргә һәм оешмаларга бүлеп бирелгән акчаларны кайтару вакытларын үтәмәгән яки шушы акчаларны тиешле максатларда файдаланмаган өчен:

- дәүләт идарәсенең җирле органнарына барлык төр финанс ярдәме күрсәтү киметелә яисә бөтенләй туктатыла;

- дәүләт идарәсенең җирле органнары бурычлары әлеге Законның 22, 28 статьяларында каралган акчалары өлешендә һәм шушы Закон нигезендә Татарстан Республикасы районнары һәм шәһәрләре бюджетларына күчерелергә тиешле Татарстан Республикасы республика бюджетының башка акчаларына карата үзара исәп-хисапларына дәгъва мөрәҗәгате белдерү юлы белән түләттерелә.

Дәүләт идарәсе җирле органнарының кире кайтару шарты белән бүлеп бирелгән акчаларны Татарстан Республикасының республика бюджетына кайтарып бирү өчен житәрлек акчалары булмаган очракта, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнары, бернинди бәхәскә юл калдырмыйча, кире кайтарылырга тиешле бурыч суммасын районнар һәм шәһәрләр бюджетлары счетларыннан Татарстан Республикасының республика бюджеты файдасына күчертергә хокуклы.

47 статья. Әлеге Законның 22 статьясы нигезендә дәүләт инвестицияләре өчен билгеләнгән чыгымнар, 2001 елга республика инвестиция программасына туры китереп, дәүләт заказчысы исемлеге буенча финанслана, дип билгеләргә (әлеге Законга 3 нче кушымта).

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты 2001 елга Татарстан Республикасының республика бюджетын үтәү барышында дәүләт капитал салулары исәбеннән 2001 ел өчен расланган күләмнәр чикләрендә төзелә торган төзелешләр һәм объектлар буенча Татарстан Республикасы республика бюджетының 2001 елның 1 гыйнварена җыелган бурычларын беренче чиратта түләттереп бетерүне тәэмин итәргә тиеш.

48 статья. Төрле дәрәҗәдәге бюджетларның акчалары исәбеннән тәэмин ителүче бюджет йөкләмәләрен билгеләүче закон актларында чыгымнарны финанслау чыганакларын бюджет системалары дәрәҗәләре буенча чикләү тәртибе урнаштырыла.

Берләштерелгән бюджетны чыгымнарны финанслау чыганагы итеп билгеләү тыела.

49 статья. 2001 елга Татарстан Республикасының республика бюджетында финанслау чыганаклары белән тәэмин ителмәгән закон актлары һәм башка норматив хокукый актлар 2001 елда үтәлмәскә тиеш.

Закон актының һәм башка норматив хокукый актның өлешчә (тулы күләмдә түгел) финанслау чыганаклары белән бюджетта тәэмин ителгән очрагында, мондый норматив хокукый акт 2001 елга Татарстан Республикасының республика бюджетында, район яисә шәһәр бюджетында һәм җирле үзидарә органы бюджетында каралган акчалар чикләрендә гамәлгә ашырыла һәм кулланыла.

2001 елга Татарстан Республикасының республика бюджеты акчалары исәбеннән өстәмә чыгымнар таләп итүче, шулай ук аның керем базасын киметүче закон актлары һәм башка норматив хокукый актлар фәкать Татарстан Республикасының республика бюджетына өстәмә кертемнәр кертү өчен тиешле чыганаклар булганда һәм (яки) 2001 елга Татарстан Республикасы республика бюджетының конкрет статьялары буенча чыгымнарны киметкәндә генә һәм шулай ук әлеге Законга тиешле үзгәрешләр кертелгәндә генә гамәлгә ашырыла һәм кулланыла.

Башкарма хакимиятнең җирле органнарына районнарның, шәһәрләрнең һәм җирле үзидарә органнарының бюджетларын үтәгәндә шундый ук принципларны куллануны тәкъдим итәргә.

50 статья. 2001 елга Татарстан Республикасы республика бюджетының тулы күләмдә финансланырга тиешле якланган агымдагы чыгымнарының түбәндәге исемлеген статьяларга: бердәм социаль салым түләүне исәпкә алып, хезмәт хакы; стипендияләр; дәүләт пособиеләре, балаларга пособиеләр түләү һәм укучыларга туклану өчен бирелгән дотация, халыкка башка социаль һәм компенсацион түләүләр; иҗат хезмәткәрләренә гонорарлар, туклану; медикаментлар һәм яраларны бәйләү чаралары сатып алу; җирле бюджетларга тапшырылучы субвенцияләр; энергетика ресурслары өчен түләү.

51 статья. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм Татарстан Республикасы Милли банкы 2001 елда Татарстан Республикасының республика һәм җирле бюджетлары чыгымнарын һәм керемнәрен исәпкә алу системасын, аларның үтәлешен оештыруны һәм аларның нәтиҗәле эшләвен тәэмин итәргә тиеш.

2001 елда Татарстан Республикасының республика бюджетын үтәү һәм җирле бюджетларның үтәлешенә исәп-хисап-касса хезмәте күрсәтү Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Бюджетларның касса үтәлеше гамәлләре, комиссион түләүләр алынмыйча гына, Татарстан Республикасының Милли банкы, "Ак

Барс" банкы һәм моңа вәкаләте башка банклар тарафыннан уздырыла.

52 статья. 2001 елда Татарстан Республикасы республика бюджетының кайбер бүлекләре буенча финанслап бетермәү бары тик 2001 елга Татарстан Республикасының республика бюджетыннан әлеге Законның 22, 28 статьяларында билгеләнгән ассигнованиеләр исәбеннән һәм чикләрендә генә компенсацияләнә.

53 статья. Бюджет һәм салым турында законнарның тулысынча үтәлешен тикшереп торуны тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасының республика бюджеты һәм җирле бюджетлар керемнәрен барлыкка китерүче чыганак булган республика һәм җирле салымнар һәм җыемнар Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнарының Татарстан Республикасының республика бюджеты һәм җирле бюджетлар акчаларын исәпкә алып бару счетларына күчереләләр, дип билгеләргә.

54 статья. Тиешле норматив хокукый актлар кабул ителгәнче, "Дәүләт хезмәте турында"гы Татарстан Республикасы Законының 13 статьясындагы 3,8,11 пунктларының, 15 статьясының гамәлдә булуга бәйле чыгымнарын башкармаска, моңа элек кабул ителгән законнар нигезендә дәүләт хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү, матди һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү чыгымнары керми.

55 статья. Татарстан Республикасы республика бюджетының предприятиеләргә, учреждениеләргә һәм оешмаларга кире кайтарып бирмәү һәм кире кайтарып бирү нигезендә бирелүче акчаларын башка максатларда файдалану әлеге суммаларны кире алу өчен һәм Россия Федерациясе Үзәк банкының гамәлдәге исәпкә алу ставкасының икеләтелгән күләмендә штраф салу өчен нигез була.

Бюджет акчаларын аларны бирү шартларында каралмаган максатларга җәлеп итү көненнән башлап, аларны Татарстан Республикасының республика бюджетына һәм җирле бюджетларга кире кайтарган яки билгеләнгән максатларга җибәргән көнгә кадәрге чор бюджет акчаларын максатчыл файдаланмаган чор дип таныла.

Татарстан Республикасы республика бюджетыннан кире кайтару нигезендә бирелүче акчаларны вакытында кире кайтармаган өчен дәүләт ярдәменең барлык рәвешләре, шул исәптән салым түләмнәрен законнар нигезендә кичектереп тору киметелә яки туктатыла.

Татарстан Республикасы республика бюджетыннан кире кайтару нигезендә алынган бурычның төп суммасын, шулай ук Татарстан Республикасы республика бюджеты акчаларыннан файдаланган өчен процентларны түләүне кичектергән өчен һәр кичектергән көн өчен

86

Россия Федерациясе Үзәк банкының гамәлдәге исәпкә алу ставкасының өч йөздән бер өлеше күләмендә пеня алына.

56 статья. Су объектларыннан файдаланган өчен түләү ставкаларын түбәндәге күләмнәрдә билгеләргә:

- билгеләнгән лимитлар чикләрендә өске су объектларыннан алынган суның бер мең куб метры өчен 80,0 сум - су алган өчен түләүчеләрдән;

- эшләп чыгарылучы электр энергиясенең бер мең киловатт-сәгате өчен 1,0 сум - гидроэлектростанцияләрне эксплуатацияләгән өчен түләүчеләрдән;

- су объектлары акваториясен кулलануның бер квадрат километр мәйданы өчен елына 5,5 мең сум - файдалы казылмалар чыгарган, оештырылган рекреация объектларын, йөзү чараларын, коммуникацияләрне, биналарны, корылмаларны, җайланмаларны һәм җиһазларны урнаштырган, шулай ук бораулау, төзелеш һәм башка төрле эшләр үткәргән өчен түләүчеләрдән;

- су объектларына агызып чыгарылучы суларның бер мең куб метры өчен 10,0 сум, - билгеләнгән лимитлар чикләрендә су агызып чыгарган өчен түләүчеләрдән.

Технологик ихтыяжлар өчен су алу һәм билгеләнгән лимитлар чикләрендә су агызып чыгару максатларында су объектларыннан файдаланган өчен түләү ставкалары җылылык энергетикасы объектларын су белән тәэмин итүнең турыга агып чыгу схемасыннан файдаланган килеш эксплуатацияләгән өчен түләүчеләргә карата су алу һәм су агызып чыгару өчен каралган ставкаларның 30 проценты күләмендә кулланыла.

Билгеләнгән лимитлардан (айлык яисә еллык) артыграк су алганда яисә агызып чыгарганда түләү ставкалары лицензия (рөхсәт) нигезендә мондый файдалануга карата билгеләнгән түләү ставкалары белән чагыштырганда биш мәртәбә арттырыла.

Су объектларыннан тиешле лицензиясез (рөхсәтсез) файдаланганда түләү ставкалары лицензия (рөхсәт) нигезендә мондый файдалануга карата билгеләнгән түләү ставкалары белән чагыштырганда биш мәртәбә арттырыла.

Су объектларыннан халыкны су белән тәэмин итү максатларында су алуга бәйле файдаланган өчен түләү ставкалары су объектыннан алынган суның бер мең куб метры өчен 30,0 сум күләмендә билгеләнә.

Су объектларыннан файдаланган өчен Татарстан Республикасының республика бюджетына түләргә тиешле өлеше өчен түләү Татарстан Республикасының республика бюджетына кертелә, моңа халыкны су белән тәэмин итү өчен өске су объектларыннан алынган су өчен түләү керми, ул түләү жирле бюджетларга тапшырыла.

57 статья. Әлеге Законны 2001 елның 1 гыйнвареннан гамәлгә кертергә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Ш.Шәймиев

Казан шәһәре
2000 елның 19 декабре
№ 512

«2001 елга Татарстан Республикасының бюджет системасы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта

2001 елга авыл хуҗалыгына акчалар бүлү

(мең сумнарда)

| Районнар исемлеге | Минераль ашламалар һәм үсемлекләрне саклау чаралары бәяләренә компенсация | | |
|---|---|---|---|
| | Барлыгы | Шул исәптән | |
| | | минераль ашламалар сатып алу өчен | үсемлекләрне саклау чараларын сатып алу өчен |
| Әгерже | 6655 | 3777 | 2878 |
| Азнакай | 18840 | 11395 | 7445 |
| Аксубай | 9725 | 5346 | 4379 |
| Актаныш | 14037 | 8055 | 5982 |
| Алексеевск | 14496 | 7912 | 6584 |
| Әлки | 8414 | 4865 | 3549 |
| Әлмәт | 13271 | 7430 | 5841 |
| Апас | 9407 | 5635 | 3772 |
| Арча | 15382 | 8371 | 7011 |
| Әтнә | 6939 | 3900 | 3039 |
| Баулы | 8212 | 4880 | 3332 |
| Балтач | 13129 | 7397 | 5732 |
| Бөгелмә | 12018 | 6689 | 5329 |
| Буа | 23398 | 14901 | 8497 |
| Югары Ослан | 5908 | 3561 | 2347 |
| Биек Тау | 11736 | 6611 | 5125 |
| Чүпрәле | 10325 | 6055 | 4270 |
| Алабуга | 8004 | 4776 | 3228 |
| Зәй | 14447 | 9419 | 5028 |
| Зеленодол | 7096 | 3999 | 3097 |
| Кайбыч | 6554 | 3591 | 2963 |
| Кама Тамагы | 5043 | 2592 | 2451 |
| Кукмара | 11292 | 6534 | 4758 |
| Лаеш | 8903 | 4914 | 3989 |
| Лениногорск | 9867 | 5768 | 4099 |
| Мамадыш | 10533 | 5707 | 4826 |
| Менделеевск | 3785 | 2013 | 1772 |
| Минзәлә | 7526 | 4137 | 3389 |
| Мөслим | 9579 | 5009 | 4570 |
| Түбән Кама | 10385 | 6281 | 4104 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Яңа Чишмә | 9230 | 4829 | 4401 |
| Нурлат | 22372 | 14694 | 7678 |
| Питрәч | 9277 | 5109 | 4168 |
| Балык Бистәсе | 9416 | 5165 | 4251 |
| Саба | 7598 | 4309 | 3289 |
| Сарман | 10835 | 5714 | 5121 |
| Спас | 9685 | 5291 | 4394 |
| Тәтеш | 8779 | 4754 | 4025 |
| Тукай | 12496 | 7678 | 4818 |
| Теләче | 6334 | 3438 | 2896 |
| Чирмешән | 10866 | 6233 | 4633 |
| Чистай | 13150 | 7360 | 5790 |
| Ютазы | 5156 | 2906 | 2250 |
| "Татплодоовощпром» концерны | 9900 | 6000 | 3900 |
| Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы | 10000 | 10000 | |
| Барлыгы | 470000 | 275000 | 195000 |

| | |
|---|---|
| Яңа техника фонды | 500000 |
| Элиталы орлыкчылыкка булышлык күрсәтү | 150000 |
| Катнаш терлек азыгы сатып алуны компенсацияләү | 160000 |
| Нәсел үрчетү һәм ясалма орлыкландыру эшенә булышлык күрсәтү | 70000 |
| Терлекчелек продукциясенә дотация | 300000 |
| Бюджет учреждениеләрен тоту һәм башка чыгымнар | 295079 |
| Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсе | 86560 |
| Барлыгы | 2031639 |

11 Pril-1

Приложение № 1

«2001 елга Татарстан Республикасының бюджет системасы турында» Татарстан Республикасы Законына
2 нче кушымта

2001 елга жир салымының Татарстан Республикасы республика бюджетына күчерелә торган өлешендәге акчаларны авыл хуҗалыгына бүлү

(мең сумнарда)

| Районнар исемлеге | Әче туфракны известьлау | Органик ашламаларны чыгару һәм кертү |
|---|---|---|
| Әгерже | 4860 | 788 |
| Азнакай | 540 | 1107 |
| Аксубай | 5700 | 701 |
| Актаныш | 8060 | 968 |
| Алексеевск | 7760 | 1224 |
| Әлки | 7350 | 501 |
| Әлмәт | 1050 | 855 |
| Апас | 3340 | 765 |
| Арча | 6170 | 2247 |
| Әтнә | 3760 | 1503 |
| Баулы | 1130 | 793 |
| Балтач | 5590 | 2261 |
| Бөгелмә | 880 | 891 |
| Буа | 3980 | 1594 |
| Югары Ослан | 2630 | 623 |
| Биек Тау | 3400 | 1606 |
| Чүпрәле | 6080 | 569 |
| Алабуга | 3950 | 1340 |
| Зәй | 4200 | 820 |
| Зеленодол | 2760 | 934 |
| Кайбыч | 3160 | 638 |
| Кама Тамагы | 1620 | 626 |
| Кукмара | 5340 | 1916 |
| Лаеш | 4670 | 1629 |
| Лениногорск | 730 | 572 |
| Мамадыш | 9060 | 2029 |
| Менделеевск | 2740 | 635 |
| Минзәлә | 6500 | 952 |
| Мөслим | 3400 | 752 |
| Түбән Кама | 4340 | 1135 |
| Яңа Чишмә | 2780 | 592 |
| Нурлат | 3450 | 1000 |

| | | |
|---|---|---|
| Питрәч | 4380 | 1242 |
| Балык Бистәсе | 5470 | 1696 |
| Саба | 5290 | 1556 |
| Сарман | 1900 | 841 |
| Спас | 6300 | 775 |
| Тәтеш | 5210 | 746 |
| Тукай | 6840 | 855 |
| Теләче | 4660 | 1347 |
| Чирмешән | 2840 | 774 |
| Чистай | 5836 | 661 |
| Ютазы | 300 | 441 |
| Районнар буенча барлыгы: | | 45500 |
| | | |
| Химизация станциясе | 3000 | |
| «Татплодоовощпром» | | 1500 |
| «Татагрохимсервис» | | 3000 |
| БАРЛЫГЫ | 183000 | 50000 |

11 Pril-2

# 2001 елга

# республика инвестиция программасы

«...Татарстан Республикасы бюджет системасы турында» Татарстан Республикасы Законына 3 нче кушымта

| Программа, инвестиция проекты һәм тармак исеме | Программаны, проектны раслаган норматив документ исеме | Программа, инвестиция проектының максаты | Финанслау чыганагы | Программа буенча барысы, 2000 ел бәяләрендә, мең сумнарда | 2001 елның 1 гыйнварена көтеләчәк үтәлеш, мең сумнарда | 2001 елга каралган, мең сумнарда | Нәтиҗәнең характеристикасы | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | Программа буенча | 1.01.2001 елга көтеләчәк үзгәреш | 2001 елга план |
| **1. Социаль үсеш** | | | | | | | | | |
| 1. 1999-2001 елларга «Татарстан балалары» республика программасы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1998 елның 22 декабрендәге 1907 нче карары | Социаль-икътисадый үзгәреш корулар чорында балалар өчен уңайлы яшәү шартлары булдыру, аларның социаль яклануын тәэмин итү | Республика бюджеты | 1480000,0 | 18000,0 | 10000,0 | | | |
| 2. Татарстан Республикасы халыклары телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасы | «Татарстан Республикасы халыклары телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау хакында» Татарстан Республикасы Югары Советы карары, 1994 ел, 20 июль, № 2192-XII | Татарстан Республикасы халыкларының телләрен үстерү | Республика бюджеты | | 27115,0 | 8100,0 | 1. Татар телен укытуны тәэмин итү (әзерлек дәрәҗәсе, процентларда)<br>100<br>2. Татар телендә укытуны тәэмин итү (әзерлек дәрәҗәсе, процентларда)<br>100<br>3. Татарстан Республикасы халыклары телләрен өйрәнүне, саклауны һәм үстерүне мәгълүмати тәэмин итү (әзерлек дәрәҗәсе, процентларда)<br>100 | 60,6<br>24,1<br>55,0 | 65,0<br>27,5<br>60,0 |
| 3. 1999-2001 елларга Татарстан Республикасында наркотик чараларны явыз ниятләрдә куллануга һәм аларның законсыз әйләнешенә каршы гамәлләрнең республика комплекслы программасы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 26 маендагы 2175 нче карары | Наркотик чараларны явыз ниятләрдә куллануны һәм аларның законсыз әйләнеше үсешен туктату өчен шартлар тудыру, дәвалау ысулларын камиллаштеру, терапевтларның үзакләрен өйрәтеру | Республика бюджеты | 159689,6 | 29200,0 | 50000,0 | | | |
| 4. «Латин графикасы нигезендә татар алфавитын торгызу турында» Татарстан Республикасы Законын (15.09.99 ел, № 2352) гамәлгә кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт программасы | «Латин графикасы нигезендә татар алфавитын торгызу турында» 1999 елның 15 сентябрендәге Татарстан Республикасы Законы (№ 2352) | Татар алфавитын латин графикасына күчерү | Республика бюджеты | 205000,0 | | 26531,0 | Татар алфавитын латин графикасына күчерү (әзерлек дәрәҗәсе, процентларда)<br>100 | 0 | 10 |
| 5. Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген арттыру программасы, шул исәптән | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы юл хәрәкәте иминлеге комиссиясе карары 31.03.97 | Юл хәрәкәте иминлеге дәрәҗәсен арттыру | ТР ЭЭМ ЮХИДИ идарәсенең юл хәрәкәте иминлеге фонды | | | 30930,0 | | | |

| Программа, инвестиция проекты һәм тармак исеме | Программаны, проектны раслаган норматив документ исеме | Программа, инвестиция проектының максаты | Финанслау чыганагы | Программа буенча барысы, 2000 ел бәяләрендә, мең сумнарда | 2001 елның 1 гыйнварына киләчәк түләүләр, мең сумнарда | 2001 елга каралган, мең сумнарда | Нәтиҗәнең характеристикасы | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | Программа буенча | 1.01.2001 елга көтелачак үзгәреш | 2001 елга план |
| *5.1. Юл хәрәкәте иминлеген арттыру гамәлләренә җәмәгать ярдәмен оештыру* | | | | | | *18222,0* | *Балалар травматизмы арту - юл-транспорт һәлакәтләре аркасында (елына ничә):*<br>- | *620* | *615* |
| *5.2. Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген оештыруны камилләштерү гамәлләре* | | | | | | *3800,0* | *Юл-транспорт һәлакәтләре саны арту (елына ничә):*<br>- | *4415* | *4410* |
| *5.3. Дәүләт техник карап чыгу станцияләре челтәрен үстерү* | | | | | | *8908,0* | *Диагностик линияләр саны (10 мең берәмлек автотранспортка - бер линия) ;*<br>*Татарстан Республикасында 767147 берәмлек автотранспорт теркәлгән*<br>*77* | *33* | *38* |
| | | Барлыгы: | | | | **125 561,0** | | | |
| **2. Инфраструктураны үстерү** | | | | | | | | | |
| **2.1. Җитештерү булмаган тармаклар инфраструктурасын үстерү** | | | | | | | | | |
| 1. Татарстан Республикасы районнарын, шәһәрләрен һәм авыл торак пунктларын табигый газ белән газлаштыру программасы | Татарстан Республикасы Президенты Указы, 08.08.95ел. № 542 | Татарстан Республикасы районнарын, шәһәрләрен һәм авыл торак пунктларын тулысынча табигый газ белән тәэмин итү. | Республика бюджеты | 5075000,0 | 1209345,0 | 250000,0 | Авылларны, шәһәр һәм эшчеләр поселокларын газ челтәре белән тәэмин итү:<br>-газүткәргечләр кертү -2670 км;<br>- фатирларны газлаштыру -37890 берәмлек<br>Газүткәргечләр озынлыгы (км)<br>14861,1<br>фатирларны газлаштыру (бер.)<br>262335<br>1.01.95 елга халәте<br>- газүткәргечләр озынлыгы – 10115,9 км<br>-газлаштырылучы фатирлар саны -792914 | 15560,5<br><br><br>296792 | 18230<br><br><br>334682 |

| Программа, инвестиция проекты һәм тармак исеме | Программаны, проектны раслаган норматив документ исеме | Программа, инвестиция проектының максаты | Финанслау чыганагы | Программа буенча барысы, 2000 ел бәяләрендә, мең сумнарда | 2001 елның 1 гыйнварена көтеләчәк түләнеш, мең сумнарда | 2001 елга каралган, мең сумнарда | Нәтиҗәнең характеристикасы | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | Программа буенча | 1.01.2001 елга көтеләчәк үзгәреш | 2001 елга план |
| 2.«Мәгариф», «Сәламәтлек саклау», «Мәдәният», торак-коммуналь хуҗалыгы һәм башка җитештерү булмаган тармаклар үсеше | | | Республика бюджеты | | | 750000,0 | 2001 елда түбәндәгеләрне файдалануга тапшырырга:<br>- 3159 уку урынлык мәктәпләр;<br>- 330 ятаклык сырхауханәләр;<br>- бер сменага 650 кеше килерлек поликлиникалар;<br>- 420 урынлык балалар бакчалары<br>Түбәндәгеләрне тәэмин итәргә.*<br>1. Тузган мәктәпләрнең санын азайту(бер.);<br>2. Ике сменада укучыларның чагыштырма зурлыгын киметү (%);<br>3. Норматив тозекләндерү белән тәэмин ителмәгән дәвалау-профилактика учреждениеләренең санын киметү;<br>4.Норматив тәэминат чикләрендә мәдәният объектларын тапшыру;<br>5. Бөек Ватан сугышында катнашучыларның торак шартын яхшырту , (кеше)<br>*Искәрмә: күрсәткечләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарында билгеләнгән | | |
| 3. Татарстан Республикасының хәрабә хәлендәге торак фондын бетерү һәм хәрабә торак кварталларны реконструкцияләү программасы | Татарстан Республикасы Президенты Указы. 03.10.95 ел, № ХII-720 | Татарстан Республикасында хәрабә хәлендәге торакларны бетерү | Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды | | | 2491000 | | | |
| 4. ТР ЭЭМның Янгынга каршы дәүләт хезмәте инфраструктурасын үстерү | | Техник җиһазлау | Татарстан Республикасының «Янгын куркынычсызлыгы» максатчыл дәүләт фонды | | | 58310 | | | |
| | | Барлысы: | | | | 3549310,0 | | | |

| Программа, инвестиция проекты һәм тармак исеме | Программаны, проектны раслаган норматив документ исеме | Программа, инвестиция проектының максаты | Финанслау чыганагы | Программа буенча барысы, 2000 ел бәяләрендә, мең сумнарда | 2001 елның 1 гыйнварена көтеләчәк түләнеш, мең сумнарда | 2001 елга каралган, мең сумнарда | Нәтиҗәнең характеристикасы | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | Программа буенча | 1.01.2001 елга көтеләчәк үзгәреш | 2001 елга план |
| **2.2. Җитештерү тармакларының инфраструктрасын үстерү** | | | | | | | | | |
| 1. Юл хуҗалыгын үстерү | | Юлларны төзү, ремонтлау һәм тоту | Республика бюджеты | | | 1756071,0 | Гомуми файдаланудагы юлларның тәэмин ителеше, 1 кв.м мәйданга, (км)<br><br>Асфальт-бетон җәелгән юлларның гомуми юллар озынлыгына чагыштырмасы, (%)<br><br>Гомуми файдаланудагы юлларга каләр асфальт-бетон җәелгән юллар белән тоташтырылмаган торак пунктларының чагыштырма күләме, (%):<br>- район үзәкләре<br>- авыл хуҗалыгы предприятиеләренең үзәк утарлары<br>- торак пунктлары – барысы: | 0,183<br><br>80,8<br><br>0<br><br>24,8<br><br>62,9 | 0,1837<br><br>80,84<br><br>0<br><br>24,8<br><br>62,9 |
| 2. Сәнәгать өчен лизинг фонды | | | Татарстан Республикасының Хосусыйлаштыру фонды | – | – | 108764,0 | | | |
| 3. Авыл хуҗалыгын техник җиһазлау фонды | | Авыл хуҗалыгы техникасы сатып алу һәм ремонтлау | Республика бюджеты | | | 500000,0 | Сатылган авыл хуҗалыгы продукциясенең үзкыйммәтендә техник җиһазлауга дотацияләрнең чагыштырма күләме, (%)<br>Белешмә: Сатылган авыл хуҗалыгы продукциясенең үзкыйммәтендәге барлык төр дотацияләрнең чагыштырма күләме - 30,1% | | 6,4 |
| | | Барлыгы: | | | | 2364835,0 | | | |
| **3. Икътисадый реаль секторының үсеше** | | | | | | | | | |

| Программа, инвестиция проекты һәм тармак исеме | Программаны, проектны раслаган норматив документ исеме | Программа, инвестиция проектының максаты | Финанслау чыганагы | Программа буенча барысы, 2000 ел бәяләрендә, мең сумнарда | 2001 елның 1 гыйнварена котелэчәк түләүләш, мең сумнарда | 2001 елга каралган, мең сумнарда | Нәтиҗәнең характеристикасы | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | Программа буенча | 1.01.2001 елга котелэчәк үзгәреш | 2001 елга план |
| 1.Фундаменталь тикшеренүләр һәм фәнни-техник прогресска ярдәм күрсәтү | | Татарстан Республикасы Фәннәр академиясен һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы ЦЭСИны финанслау | Республика бюджеты,<br>НИОКР фонды | | | 46043,0<br><br>28000,0 | Түбәндәге фәнни юнәлешләр буенча фундаменталь тикшеренүләрнең нәтиҗәләре<br><br>- Татар халкы һәм Татарстан халыклары: янарыш һәм үсеш;<br><br>- Татарстан Республикасы иҗтимагый үсешенең төп тенденцияләре;<br><br>- Медицина һәм биология фәннәре;<br><br>- Агросәнәгать житештерүенең нәтиҗәлелеге;<br><br>- Математика, мәгълүмати технология, механика һәм машина төзелеше;<br><br>- Физика һәм энергетика өлкәсендә перспектив материаллар һәм технологияләр;<br><br>- Химиянең фундаменталь нигезләре һәм яна югары химик технологияләр эшкәрү;<br><br>- Ягулык-энергетика һәм чимал ресурслары, аларны үзләштерүдә энергияне саклау технологияләре;<br><br>- Татарстан Республикасының экологик иминлеге | | |
| 2. Спирт сәнагате үсеше | | Тармак предприятиеләрен реконструкцияләү һәм модернизацияләү | Республика бюджеты | | | 90000,0 | Буа спирт заводын төзү<br>- башлангычы<br>- әзерлек дәрәҗәсе (%)<br><br>100 | 38,8 | 100 |

| Программа, инвестиция проекты һәм тармак исеме | Программаны, проектны раслаган норматив документ исеме | Программа, инвестиция проектының максаты | Финанслау чыганагы | Программа буенча барысы, 2000 ел бәяләрендә, мең сумнарда | 2001 елның 1 гыйнварена көтелачак түләнеш, мең сумнарда | 2001 елга каралган, мең сумнарда | Нәтиҗәнең характеристикасы | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | Программа буенча | 1.01.2001 елга көтеләчәк үзгәреш | 2001 елга план |
| 3. Татарстан Республикасының минерал-чимал базасын өйрәнү һәм торгызу | | 1. Файдалы казылмаларның перспектив мәйданнарын һәм урыннарын эзләү һәм бәяләү, сирәк очрый торган файдалы казылмаларны, шулай ук торфны, сапропельне, эчәр җир асты суларын һәм минераль суларны һәм башка файдалы казылмаларны разведкалау<br>2. Чыганакларны фаразлау, эзләү, разведкалауның ысулларын эшләү һәм тамалга кертү<br>3. Җир асты байлыкларын, җир асты суларын һәм әйләнә-тирә мохитне саклау | Республика бюджеты | | | 2200000,0 | Җир асты сулары запасының уртача еллык үсеше (%): | | |
| | | | | | | | 20 | 20 | 20 |
| | | | | | | | Нефть запаслары үсешенең һәм аны ел саен чыгару күләменең чагыштырмасы (%) | | |
| | | | | | | | | 100 | 100 |
| 4. Икътисадның реаль секторының инвестиция үсеше :<br><br>Остенлекле инвестиция проектларын финанслау | | Предприятиеләрнең икътисадый яктан үз-үзләрен тәэмин итү дәрәҗәсен тәэмин итү | Татарстан Республикасының Хосусыйлаштыру фонды. ИНОКР фонды | | | 332780,0 | Зарарга эшләүче предприятиеләр өлеше (%) | | |
| | | | | | | | | 40,0 | 38,0 |

| Программа, инвестиция проекты һәм тармак исеме | Программаны, проектны раслаган норматив документ исеме | Программа, инвестиция проектының максаты | Финанслау чыганагы | Программа буенча барысы, 2000 ел бәяләрендә, мең сумнарда | 2001 елның 1 гыйнварена көтеләчәк үтәлеш, мең сумнарда | 2001 елга каралган, мең сумнарда | Нәтиҗәнең характеристикасы | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | Программа буенча | 1.01.2001 елга көтеләчәк үзгәреш | 2001 елга план |
| *шул исәптән, «Татарстан Республикасында энергияне сак тоту буенча 2000-2005 елларга» максатчыл республика программасы* | *Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты 03.07.2000 ел, №468* | *Энергияне сак тоту буенча алдынгы фәнни технологияне гамәлгә кертү, ЯЭ комплексында, сәнәгадә, авыл хуҗалыгында һәм икътисадның башка тармакларында ягулык-энергетика ресурсларын куллануның чагыштырма күләме* | *Татарстан Республикасының Хосусыйлаштыру фонды* | *2000000,0* | *152600,0* | *108000,0* | 1. Продукция житештерүгә тотылган энергиягә чыгымнарның житештерелгән товар продукциясе чыгымнарына чагыштырмасы (%):<br>9,45 10,55 10,23<br>шул исәптән:<br>- машина төзелеше һәм металл эшкәртү<br>9,34 10,6 10,07<br>- химия һәм нефть химиясе<br>19,63 21,08 20,66<br>- ягулык сәнагате<br>7,36 8,89 8,45<br>- авыл хуҗалыгы<br>3,20 3,81 3,75<br>2. Торак-коммуналь хуҗалыклары һәм бюджет оешмалары тарафыннан электр энергиясе куллануның аларның гомуми мәйданына чагыштырмасы (мең кВтч/$м^2$)<br>13,87 17,25 16,87<br>*3. Торак-коммуналь хуҗалыклары һәм бюджет оешмалары тарафыннан ягулык энергиясен куллануның аларның гомуми мәйданына чагыштырмасы (Гкал/мең.$м^2$)*<br>198,0 246,3 240,8<br>4. Шартлы ягулыкның энергия житештерүчеләр тарафыннан тотылучы массасының алар биргән электр энергиясенә чагыштырмасы (кг/кВтч)<br>346,2 347,9 347,6<br>5. Шартлы ягулыкның энергия житештерүчеләр тарафыннан тотылучы массасының алар биргән ягулык энергиясенә чагыштырмасы. (кг/Гкал)<br>142,3 143,1 142,9 | | |
| 5. Татарстан Республикасында кече эшкуарлыкка ярдәм итү | | Кече предприятиеләрнең проектларын финанслау | Татарстан Республикасы Хосусыйлаштыру фонды | | | 21700,0 | Кече предприятиеләр санын арттыру (бер.) | 250 | 140 |
| | | Барлыгы: | | | | 2718523,0 | | | |
| **4. Әйләнә-тирә мохитне саклау** | | | | | | | | | |
| Әйләнә-тирә табигать мохитен һәм табигый байлыкларны саклау буенча гамәлләрне финанслау - барысы | | | Татарстан Республикасының Экология фонды | | | 251720,0 | | | |

| Программа, инвестиция проекты һәм тармак исеме | Программаны, проектны раслаган норматив документ исеме | Программа, инвестиция проектының максаты | Финанслау чыганагы | Программа буенча барысы, 2000 ел бәяләрендә, мең сумнарда | 2001 елның 1 гыйнварена котеләчәк үтәлеш, мең сумнарда | 2001 елга каралган, мең сумнарда | Нәтиҗәләр характеристикасы: Программа буенча | 1.01.2001 елга котеләчәк үзгәреш | 2001 елга план |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| шул исәптән: | | | | | | | | | |
| 1. Халыкның экологик имилеген тәэмин итү буенча максатчыл комплекслы программалар, шул исәптән: | | Халыкның экологик имилеген тәэмин итү | | | | | | | |
| 1.1. Татарстан Республикасының атмосфера һавасын саклау (1997-2001 еллар) | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, 17.02.97 ел., № 127 | Атмосферага ычкынган матдәләр чыгару күләмнәрен киметү | Татарстан Республикасының Экология фонды | 226090.0 | 24189.0 | 8288.0 | | | |
| 1.2. Су ресурсларын саклау һәм алардан нәтиҗәле файдалану (1997-2001 еллар) | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, 17.02.97 ел. №127 | Су ресурсларын пычрату күләмнәрен киметү | Татарстан Республикасының Экология фонды | 719638.0 | 130500.0 | 39539.0 | Биологик чистарту корылмаларын гамәлгә кертү (тәүлегенә мең куб.м): 100 | 1.0 | 15.0 |
| | | | | | | | Биологик чистарту корылмаларын реконструкцияләү (объектлар саны): 15 | 0 | 5 |
| | | | | | | | Бүлеп бирелүче гомуми су күләмендә норматив чиста һәм норматив чистартылган су өлеше (%): 19.5 | 18.0 | 19.2 |
| 1.3. Татарстан Республикасының авыл хуҗалыгы комплексында табигать байлыкларын саклау һәм торгызу (1997-2001 еллар) | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, 17.02.97 ел. №127 | Деградацияләнгән табигать комплексларын торгызу яңа белән табигать байлыкларын ишәйтү, биологик төрлелекне саклау. Махсус сакланылучы табигать территорияләре челтәрен үстерү | Татарстан Республикасының Экология фонды | 593251.0 | 17420.0 | 13262.0 | Махсус сакланылучы табигать территорияләре бүлеп бирелгән җир мәйданнары булган районнарның гомуми районнарының оптималь санынан тубән өлеше: 33.4 | 36.4 | 35.4 |
| 1.4. Татарстан Республикасы халкының экологик белеме (1997-2001 еллар) | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, 17.02.97 ел. №127 | Халыкның экологик аңын формалаштыру | Татарстан Республикасының Экология фонды | 82225.0 | 15100.0 | 5800.0 | Татарстан Республикасы гражданнарының экологик компетенциясен күтәрү, республикада экологик хәлләрне яхшырту шартларын булдыру һәм табигатьне саклау гадәтләрен әзерләү системасын бүген сыйфатлы дәрәҗәгә күчерү. Экологик белем дәрәҗәсен күтәргән кешеләр саны (кеше): 1610 | 270 | 380 |
| 1.5. Татарстан Республикасында нефть продуктларын файдалы эшкә тотү (1997-2001 еллар) | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, 17.02.97 ел. №127 | Әйләнә-тирә мохитне пычрату күләмнәрен киметү | Татарстан Республикасының Экология фонды | 10396.0 | 1200.0 | 1920.0 | Нефть продуктлары калдыкларын эшкәртү күләмнәрен арттыру (%): 50 | 30 | 40 |
| 1.6. Татарстан Республикасы әйләнә-тирә табигать мохите мониторингы (1997-2001 еллар) | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, 17.02.97 ел. №127 | Дәүләт хакимияте органнарын мәгълүмати-аналитик тәэмин итү максатында әйләнә-тирә мониторинг системасын үстерү | Татарстан Республикасының Экология фонды | 310763.0 | 7400.0 | 10060.0 | Әйләнә-тирә мохитне һәлакәтләр белән пычратуга бәйле гадәттән тыш хәлләрнең сәбәпләрен анализлау һәм нәтиҗәләрен фаразлау, оператив ачыклау системасын булдыру максатында Татарстан Республикасының табигать мохитен пычратучы ингредиентларны үлчәү өчен автоматлаштырылган чаралар кертү | | |

100

| Программа, инвестиция проекты һәм тармак исеме | Программаны, проектны раслаган норматив документ исеме | Программа, инвестиция проектының максаты | Финанслау чыганагы | Программа буенча барысы, 2000 ел бәяләрендә, мең сумнарда | 2001 елның 1 гыйнварена кадәр түләнеш, мең сумнарда | 2001 елга каралган, мең сумнарда | [illegible] | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | Программа буенча | 1.01.2001 елга кадәр үзгәреш | 2001 елга план |
| *2. Татарстан Республикасында имәнлекләрне торгызу программасы (1996-2000 еллар)* | *Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, 24.05.96 ел, № 419* | *Республиканың имәнле урманнарын торгызу һәм саклау* | *Татарстан Республикасының Экология фонды* | *124544,0* | *5560,0* | *4960,0* | *Урман белән капланган мәйданнарны саклау* | | |
| | | | | | | | *1,0* | *1,0* | *1,0* |
| | | | | | | | *Яклау функциясен башкаручы урманнарны саклау, урманнарның гомуми мәйданнарына %ларда* | | |
| | | | | | | | *0,42* | *0,42* | *0,42* |
| 3. Татарстан Республикасында атмосферага автотранспорт чараларыннан агулы матдәләр чыгаруны киметү программасы | *Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, 19.05.95 ел, № 419* | *Татарстан Республикасында атмосферага автотранспорт чараларыннан зарарлы матдәләр чыгаруны киметү* | *Татарстан Республикасының Экология фонды* | *61123,0* | *1515,0* | *12137,0* | *Эшкәртелгән газларда агулыгын һәм төтенен арттырып атмосферага чыгаручы автотранспортның гомуми автотранспорт санына карата өлеше (%)* | | |
| | | | | | | | *19* | *12,5* | *12,0* |
| *4. Калдыкларны [illegible] утильләштерү һәм [illegible] (1999-2002 еллар)* | *Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, [illegible]* | *Әйләнә-тирә мохитне пычрату күләмнәрен киметү* | *Татарстан Республикасының Экология фонды* | *858943,0* | *29950,0* | *155754,0* | *Каты көнкүреш калдыклары полигоннарын булдыру (берәмлекләр):* | | |
| | | | | | | | *51* | *17* | *16* |
| | | | | | | | *күләм (мең м3)* | | |
| | | | | | | | *[illegible]* | *4573* | *4390* |
| | | Итого: | | 2986973,0 | 232834,0 | 251720 | | | |

**2001 елга Республика инвестиция программасы буенча барлыгы - 9 009 949,0**

11 Pril-3